АЙСЫЛУ ЛОТФУЛЛИНА:
«Исememне истә калдыра алмаган балалар «Татарский» дип йөртә иде»

> 4

ИЛГИЗ ЗӘЙНИ:
«Дәүләт театры – атаңнан калган мал түгел, кайда һәм ничек эшләгәнеңне чамаларга кирәк»

> 6

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК
Укучыларыбызның уй-фикерләре, истәлекләре

> 7

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА
Балалар һәм ата-аналар өчен махсус сәхифә

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 139–140 (29106–29107) | Сишәмбе | 26 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

ИСРАФ БУЛМАСЫН

Берничә көн элек интернет челтәрендә Арча районының «Кырлай» хуҗалыгы кырларында өем-өем булып яткан бәрәңгеләрне төшергән видеоязма таралды. Әлеге видеодан аңлашылганча, кырда бәрәңгенең эресе дә, вагы да бар. «Никадәрле бәрәңгене әрәм итеп ташлаганнар!» – ди видеога төшерүче. Кемнәрдер хуҗалык җитәкчелеген исрафчылыкта гаепләсә, икенче берәүләр аны, узган ел уңышы булырга мөмкин, дип фаразлады.

vk.com / фото бизәү өчен бирелде

Кызганыч, «ВТ» хәбәрчесе «Кырлай» хуҗалыгы җитәкчесе Марат Кәримовка берничә тапкыр шалтыратып, язып караса да, җавап ала алмады. Шуңа күрә без районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Ленар Абдуллин белән сөйләштек.

– Видеода күренгән бәрәңгеләр аралаганнан калган. Алар йә имгәнгән, йә чери башлаган. Хуҗалык, бәрәңгене алганнан соң, складка кайтара. Шунда аларны аралап, утыртуга дигәнен – утыртуга, сатуга дигәнен сатуга алып калалар да начаррак бәрәңгеләрне басуга кире китерәләр. Бәрәңгеләрнең шулай ятуы – вакытлыча гына күренеш. Гадәттә тараталар һәм туфрак белән бергә эшкәртәләр. Кирәк кеше хайванына булса да җыеп алсын, дип тә таратмыйча торганнар иде, – диде Ленар Абдуллин.

Яшерен-батырын түгел, кибетләргә, мәктәп һәм мәктәпкәчә учреждениеләргә билгеле бер таләпләргә туры килгән яшелчәләрне генә кабул итәләр. Зур хуҗалыклар яньчелеп ямьсезләнгән яки бозыла башлаган бәрәңге һәм башка яшелчәләрне нишләтә соң?

Әйтик, Буа районының Аксу авылында 45 гектар мәйданда кишер, бәрәңге, чөгендер үстерүче Фирдүс Салаватуллин да андый яшелчәләр булуын яшерми, тик аларның берсе дә әрәм булмый, ди ул.

– Без сатуга яраксыз булган бәрәңгене 2 сум 80 тиенгә Чувашиядәге крахмал заводына алып барып тапшырабыз. Кишерне атларга бирәбез. Сатылмаган чөгендерне ташлаган вакытлар да бар. Аны тагын нишләтеп була инде? Арада черегән, бозылган яшелчәләр дә очрый. Аларын, билгеле, түгәбез. Рөхсәт сорап, авыл халкы да терлекләренә, атларына җыеп алып китә. Алардан артканы кырда ашлама буларак кала. Яхшы хәлдәгеләрне арзанрак бәягә сатып та бирәбез. Шуңа күрә бездә берни дә исраф булмый, – диде Фирдүс Салаватуллин.

Чүпрәле районы фермеры, «Дуван бакчалары» авыл хуҗалыгы кооперативы җитәкчесе Альфред Хәйруллин зур хуҗалыгында алма, виктория, кура җиләге, карлыган үстерә.

– Быел алмагачларыбыз беренче генә ел уңыш бирә. Чамадан тыш артык уңышны кая куярга белмичә аптырап торганыбыз юк анысы. Сатуга көненә 10 тоннага кадәр алма озатабыз. Төрле кибетләрдә, ярминкәләрдә, авылларда машиналар белән сату оештырылган. Җиләк, карлыган кебек җиләк-җимешләрне дә вакытында сатып бетереп барабыз. Әле җитми дә кала. Бераз гына ямьсезләнә башласа, бәясен төшерәбез дә тиз арада сатып бетерү ягын кайгыртабыз, – диде ул.

Моннан тыш, алар балалар йортларына да җиләк-җимеш һәм аларның кайнатмаларын сәдака итеп тапшыра.

– Шулай ук хәрби операциядә катнашучы егетләребезгә дә әледән-әле күчтәнәчләр җибәреп торабыз. Әле менә күптән түгел генә алма, кайнатмалар юлладык. Матди ярдәмне дә, кирәк-яракны да даими рәвештә җибәрәбез. Районда чаралар да безнең бакчаларда үскән җиләк-җимештән башка узмый. Шуңа күрә үзебез үстергәнне чүплеккә илтеп ташлау – безнең өчен бөтенләй ят күренеш, – диде Альфред Хәйруллин.

Бәрәңге сатылып бетә, кәбестәне урнаштыру авыррак. Чистай районының Кызыл Ялан авылында яшелчәчелек белән шөгыльләнүче бертуган Сабировлар әнә шулай ди.

– Узган ел кәбестәне сату авыр барганлыктан, суыклар төшкәнче җыеп алып бетереп булмады. Шунлыктан бер өлеше басуда ятып калды. Бу күпмедер дәрәҗәдә мәҗбүри эшләнгән эш иде, чөнки саклар өчен шартлар булмады, – диде Алмаз Сабиров. – Билгеле, күп тырышлык куеп үстергән уңышыбыз яхшы бәядән тиз арада урнашып бетсә, бик әйбәт. Тик ел да без теләгәнчә генә булмый шул.

Быел яңгыр булмагач, кәбестә уңышының бик сөендермәвен әйтте фермер. Гадәттә уртача кәбестә 3 кг авырлыкта булса, быел 1–1,5 кг гына икән.

– Бәрәңге бик тиз урнашып бетте. Бераз вагы, ямьсезләнгәннәрен кырда калдырдык да авылдашларга терлекләренә булса да җыеп алырга әйттек. Тик җыйган кеше күп булмады. Чөнки, дөресен әйткәндә, андый бәрәңгенең файдасына караганда мәшәкате күбрәк, – диде Алмаз Сабиров.

Артыгын түләткәннәр

Россиянең 23 төбәгендә, халыкның электр уты белән начар тәэмин ителүе сәбәпле, «коммуналка» түләвен яңадан исәпләгәннәр. Кремльнең матбугат хезмәте хәбәренә караганда, Генераль прокуратура оештырган тикшерү барышында ачыкланганча, электр уты бирүче оешмалар кешеләрдән 5 миллиард сумнан күбрәк акча түләткән.

Генераль прокурор Игорь Краснов Россия Президенты Владимир Путин белән очрашуда шул хакта сөйләп үткән. «Быел электр энергетикасы, газ белән тәэмин итү өлкәсендәге законнарны үтәү өлкәсендә тикшерү үткәрдек. Аның нәтиҗәсендә ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларның 5 миллиард сумнан күбрәк күләмдәге чыгымнарының нигезсез булуы ачыкланды. Асылда халык түләгән акча бу», – дигән Игорь Краснов. Ул шулай ук алдагы ике елга тарифларның 4 миллиард сумнан күбрәккә киметелүен дә билгеләп үткән.

Безнең егетләр өчен

Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте махсус хәрби операция зонасына инде менә өченче тапкыр гуманитар йөк юллаган. Нәзарәт вәкилләре бу юлы 1 тонна чамасы йөкне турыдан-туры хәрбиләр кулына тапшырган.

Алар өчен караңгыда күрү приборлары, радиостанцияләр, маскировка челтәрләре, бронежилет, шлем, колакчын, фонарь, компас, газ плитәсе һәм баллоннар, эш кораллары, җылыткыч материаллар сатып алынган. Шулай ук республикадан киткән ир-егетләргә хәләл тушенка, гигиена әйберләре, дарулар, эчке кием китерелгән.

Диния нәзарәтеннән искәртеп үтелгәнчә, йөк Луганск өлкәсендәге хәрби подразделениегә тапшырылган. Биредәге солдатларның 90 проценты – Татарстаннан: Биектау, Питрәч, Саба, Арча, Балык Бистәсе районнарыннан һәм Казаннан. Гуманитар йөк нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды җыйган акча хисабына сатып алынган. Акча җыю дәвам итә.

Сөбханалла!

Быел Казанда яшәүче 55 кеше 100 яшькә җитәчәк һәм аннан да узып китәчәк. Шуның 51е – әби, дүртесе – бабай.

Россия Социаль фонды мәгълүматларына караганда, 2023 елның 1 гыйнварына Казанда барлыгы 291512 кеше иминият пенсиясе алган. Шуның 70 процենттан артыграгы – хатын-кызлар, 28,4 проценты – ир-атлар.

Башкалабызда яшәүче 42814 кешенең яше – сиксәннән өстә. Казан башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова әйтүенчә, соңгы биш ел эчендә шәһәрдә 80нән узучылар саны 3 меңгә диярлек арткан. 1266 кешегә өендә социаль хезмәт күрсәтелә.

Иртәгә – тагын «җәй»

Татарстанга салкынча һава агымы үтеп керде. Аз-маз яңгырлар да явып үтәчәк. Әмма инде чәршәмбедән явым-төшеп туктап, сентябрь ахырына кадәр бик җылы һава урнашачак.

Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе – 27–28 сентябрьдә республикада яңгыр ихтималы аз. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +17…+22 градуска кадәр күтәреләчәк. Төнлә исә +2…+8 градус күрсәтәчәк.

Синоптикларның башлангыч фаразы буенча, җомга һәм шимбә – 29–30 сентябрьдә бик җылы, коры һава саклана. Көндезге температура +19…+24 градус чикләрендә тирбәләчәк.

Сәламәтлек

Әйләнә дә килә

ТАТАРСТАНДА ВИРУСЛЫ ЧИРЛӘР БЕЛӘН АВЫРУЧЫЛАР САНЫ АРТА

Көз җитүен сары яфраклар, һава торышы үзгәрешләреннән генә түгел, вируслы авыруларның баш калкытуыннан да аңларга була. Соңгы арада республикада кискен респиратор вируслы инфекцияләр һәм грипп белән авыручылар саны арту күзәтелә. Элеккеге «дус» коронавирус та – алар рәтендә.

Соңгы мәгълүматлар буенча, чирләүчеләр күрсәткече 46 процентка арткан – 14 мең 215 очрак. Коронавирус инфекциясе белән авыручылар саны бер атна эчендә 89га җиткән. Моңа кадәр 65 очрак иде. Шунысы куандыра: әлегә йогышлы чирләр җиңел формада уза. Әмма моңа карап кына тынычланырга ярамый. Әнә кайбер төбәкләрдә инде ковид госпитальләре дә яңадан эшли башлаган, битлек киюне дә кире кайтарганнар. Республикада мондый чикләү чараларын кулланырга җыенмыйлар әле анысы. Шулай да «Барысы да үзебездән тора» дигән сүзне искә төшерер вакыт.

Хөкүмәт йортында узган «шимбә киңәшмәсе»ндә дә «әйдә, ярый» дип кенә, сәламәтлеккә битараф булмаска өндәделәр. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республикада яшәүчеләрне профилактика чараларына җитди карарга кушты.

– Профилактик чараларның берсе – вакцинация, – диде Рәис. – Республикага гриппка каршы 824 мең доза вакцина кайтартылды. Чирләүчеләр арту сәбәпле, республика халкының 60 процентына прививка ясату кирәк. Хәзерге вакытта 573 мең кеше вакцинация узган.

Сүз уңаеннан, Татарстанда вакцинаны сырхауханәләрдә генә түгел, метро станцияләре янында да ясыйлар. Казанда моның өчен махсус мобиль пунктлар эшли.

Прививка белән генә чикләнәсе түгел, әлбәттә. Республика Рәисе, чирнең белем бирү оешмаларына һәм хезмәт коллективларына үтеп керүен булдырмас өчен, барысын да эшләргә кушты. Аерым алганда, бу – иртәнге фильтрлар, ОРВИ билгеләре булганда битлек кию, гигиена таләпләрен үтәү һәм антисептик куллану.

Белгечләр, җылы һава торышы булганда вакцина ясатып калу кулайрак, дип кисәтә. Сезонлы чирләр күтәрелеше башланганчы, моны өлкән яшьтәгеләргә, балаларга һәм йөкле хатын-кызларга аеруча киңәш итәләр.

Табиб-терапевт Олег Абакумов әйтүенчә, чир йоктырмас өчен, нык иммунитет кирәк. Иммунитетның ныклыгы исә нәрсә ашавыбызга да бәйле.

– Туклану рационында омега-3 һәм D витамины кергән азык-төлек булырга тиеш. Болар балыкта бар. Иммунитетны ныгыту өчен аксым да мөһим, ул сыер ите, тавык түше, күркә итендә бар, – дип киңәш итә белгеч. – Яшелчәләр ашау, минераль су эчү дә булышыр. Гигиена таләпләрен үтәү дә бик мөһим.

Сүзгә-сүз

er.ru

Антон НЕМКИН, Дәүләт Думасының мәгълүмати сәясәт, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә комитеты әгъзасы:

Блоклауны урап узарга ярдәм итүче сайтлар белән көрәш – халыкны нәрсәдәдер чикләргә омтылу түгел. Киресенчә, кулланучыны шәхси мәгълүматларның югалуыннан, төрле күңелсезлекләрдән саклау ул.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ИПОТЕКА

2023 елның гыйнвар – август айларында Татарстанда 80 меңгә якын ипотека килешүе төзелгән. Бу хакта Росреестрның республика буенча идарәсе хәбәр итә.

Үсеш – 35 процент
28,1 меңнән ↗ 38 меңгә
(торак ипотекасы)

Үсеш – 32 процент
20,6 меңнән ↗ 27,1 меңгә
(җир участокларына)



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЗАНГЕЗУР – ЯҢА ТӨЕНМЕ?

Карабах төенен чабып өзү Көньяк Кавказдагы киеренкелекне киметте, әмма тулысынча юкка чыгармады. Азәрбайҗан хакимиятләре тәбәктәге әрмән көчләрен коралсызландыру, Әрмәнстанга күчәргә теләүчеләргә гуманитар коридор тәэмин итү белән мәшгуль. Туган җирләрендә яшәп калырга теләүчеләргә иминлек гарантияләү дә мөһим.

Ереванның үзендә радикаль милләтче көчләр котырына. Пашинянны хакимлектән тартып төшерергә теләп, масштаблы акцияләр оештырыла. Полиция көчләре иң актив гыйсъянчыларны кулга алу белән мәшгуль. Пашинян идарәдән китмәячәген белдерә. Хакимлекне саклый алган очракта, әрмән лидерына Азәрбайҗан белән тыныч килешүне имзаларга кирәк булачак. Килешү, ике илнең хезмәттәшлеген җайга салып, мөнәсәбәтләрне үсеш һәм чәчәк ату рельсларына күчерә алыр, ике халык өчен дә файдалы булыр иде. Әмма вазгыять лидерның җаваплылыгы өстенлек алган карашларга никадәр бәйле булуын сурәтли. Бик катлаулы төбәк бу. Тарих битләрен ачып карасаң, чачләрен үрә торырлык хәлләр белән тулы. Гасырлар буе канлы көрәш тынмаган, фарсы, төрек, әрмән – азәрбайҗан мәнфәгатьләре узара киселеп беткән, Россия максатлары белән сугарылган төбәк. Пашинян – Россия белән араны өзеп, Көнбатыш канаты астына керү тарафдары. Мәскәүдә моның белән килешмәячәкләр, билгеле.

Мөнәсәбәтләрне Зангезур коридоры дип аталган, Әрмәнстанның Сюник төбәге аша үтә торган юл кискенләштерә. Картага карасак, Нахичевань Автономияле Республикасының (Азәрбайҗан составындагы республика) төп төбәктән әрмәннәрнең Сюник өлкәсе белән бүленгәнен күрер идек. Баку Ереванннан Нахичеваньга транспорт коридоры ачуны таләп итә. Коридор ачылса, Азәрбайҗанның Төркиягә дә коры җир аша бару җиңелләшә. Әнкара белән Баку киләчәктә шул тәбәктән газ торбалары үткәрү идеясе белән дә яналар. Бу идея Россия мәнфәгатьләренә китереп суга. Бердән, Урта Азия газын Мәскәү катнашыннан башка гына Төркиягә һәм Европага илтү мөмкинлеге бирә, икенчедән, Кремль теләгән газ хабы проектын юкка чыгара. Житмәсә, Әрмәнстанга Россия газына бәйлелектән котылырга мөмкинлек бирә. Зангезур коридорына Иранда да бик шатланмыйлар. Күрәсезме, күпме мәнфәгатьләр чәбәләнеп беткән. Төрек матбугаты әрмән көчләренең Карабахтан Зангезур коридорына илтеп ташлануы, анда зур сугыш көтелүе турында яза. 5 октябрьдә Алиев, Пашинян һәм Әрдоганның Гранадада очрашуы булырга тиеш. Баку һәм Әнкара, җиңүчеләр буларак, үз шартларында килешү әзерләргә тырышачаклар. Төбәкнең башка уенчылары ни әйтер тагын?

Россиядә

ГАЗ КЫЙММӘТЛӘНЕР, УТ ТА КАЛЫШМАС

Федераль хөкүмәт 2024 елга бюджет төзи. Без илдә тотрыклылык, санкцияләрнең безгә зыян салмавы, кересенчә, үсешкә генә этәрүе турындагы сүзләр белән килешәбез. Әмма бюджет параметрлары да, киләчәккә планлаштырылган тарифлар да халыкка җиңеллек вәгъдә итми.

Казнаның төп чишмәсе булган нефть кыйммәтләнә, Россия саткан нефтьнең байтак өлеше түшәмне ватып чыгып сатыла. Агымдагы вазгыять керемнәрнең артачагын вәгъдә итә. Әмма чыгымнар, керемнәрне дә узып, алга ыргыла. Хәрби чыгымнарны кискен күтәрергә вәгъдә итәләр. Алар 2023 елда әчке тулай продуктның 3,9 процентын тәшкил итсә, киләсе елга 6 процентка җитәргә тиеш. Чагыштырыгыз: НАТО илләре оброна максатларына ЭТПның 2 процентын сарыф итә. Бюджетның яшерен статьяларына быел 6,5 триллион сум каралган булса, киләсе елга 10,8 триллионга җиткерелер. Хөкүмәт социаль өлкәне дә онытмый. Пенсияләр һәм социаль түләүләр арттырылачак. Ләкин күпчелек халыкның кесәсендә барыбер җилләр уйнар.

2024 елга газга, утка, суга тарифлар рекордлы рәвештә үсәчәк. Федераль хөкүмәт коммуналь тарифларның үсү графигын игълан итте. Үткән елның июле белән 2024 елның июле арасында коммуналь тарифлар үсеше 26 процент булыр дип көтелә. Бу бәянең бер елга уртача 12 процентка үсешенә тиң икән. Росстат игълан иткән инфляциянe күпкә узып китә. Хөкүмәт моны «табигый газ белән барлык категория кулланучыларны ышанычлы тәэмин итү» һәм «социаль газ кертү программасын дәвам иттерү» максатларыннан эшләнә дип аңлата. Максатларның изге булуы кесәләргә җиңеллек китерми. Башка куллану товарлары да кыйммәтләнми калмаячак бит. Чит илләргә газ сату кимеде, углеводородлар чыгару күләме дә кечерәя. Эчке базарны тышкы базардан алган табыш хисабына субсидияләү кыен хәзер. «Газпром», Европа базарын югалтып, 40 миллиард доллар акчадан колак какты, диләр. Югалтуны каплыйк дисәк, эчке базарда газ куллануны 4 тапкыр арттырырга яисә бәяләрне 4 тапкыр күтәрергә кирәк булачак икән. Тагын бер хисап бар: һәрбер россияле «Газпром»га бер елга 22,6 мең сум түләсә, табигый монополия Көнбатыш белән саубуллашу ачысын татымаячак. Утка, суга, җылылыкка тарифлар да кискен үсә. Тагын бер нәрсә бар: төбәкләр федераль хөкүмәт тарифларыннан да уздырып җибәрә. Димәк, акчаны бик санап тотарга туры килер.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ТИРӘН ТАМЫРЛАР

Татарлар белән казахларның хезмәттәшлек тамырлары тирән. Бу эш гасырлар буе барган һәм хәзер дә дәвам итә. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Казахстандагы эшлекле форум барышында шулай дип белдерде. Республика Рәисе биредә «Иннопром» күргәзмәсе һәм «Яңа заманның сәнәгать стратегияләре» пленар сессиясендә катнашу өчен килде.



tatarstan.ru

Казахстанга эш сәфәре кысасында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Казахстан Президенты Касыйм Жомарт Токаев белән очрашты. Очрашу вакытында ике як та хәзерге вакытта Казахстан территориясендә гамәлгә ашырыла торган уртак проектлар турында фикер алышты.

– Хезмәттәшлек өчен мөмкинлекләр күп, беренче чиратта, икътисад өлкәсендә. Ел саен товар әйләнеше артуга карамастан, без әлегә барлык мөмкинлекләрне дә тулысынча кулланмыйбыз. Әлеге эшне көчәйтергә кирәк, – диде Рәис.

Моннан тыш ике арадагы мәдәният, фән, мәгариф, туризм һәм спорт өлкәләрендә үзара хезмәттәшлекне үстерүнең мөһимлеге дә ассызыкланды.

– Татарстан вузларында Казахстаннан 1200дән артык студент белем ала. Республикада казахларның милли-мәдәни автономиясе актив эшли. Казахстан территориясендә яшәүче татар җәмәгатьчелегенә 200 меңнән артык кеше керә. Аларга ярдәм иткәнегез өчен аерым рәхмәт белдерәсем килә, – диде Рәис.

– Татарлар һәм казахларның хезмәттәшлек итү тамырлары тирән. Безне дин, телләр һәм мәдәниятләр охшашлыгы да якынайта. Бүген Казахстан – Татарстанның әйдәп баручы партнерларының берсе, – диде Рөстәм Миңнеханов. Узган ел безнең товар әйләнеше 20 процентка артып, 758 млн долларга җитте. Агымдагы елның беренче яртыеллыгында үзара сәүдә тагын 40 процентка артып, 437 миллион долларны тәшкил итте.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстан компанияләре Казахстанда шактый актив эшли.

– Без Казахстан белән хезмәттәшлекнең өстенлекле юнәлешләре дип энергетика, сәнәгать һәм станоклар төзү, автомобиль төзелеше һәм транспорт, вертолетлар төзү, газ-мотор ягулыгы, нефть химиясе, авыл хуҗалыгы һәм хәләл индустрия, төзелеш, мәгълүматлаштыру өлкәләрен күрәбез, – дип белдерде Рөстәм Миңнеханов үзенең чыгышында.

Белешмә өчен

◆«Иннопром» күргәзмәсе Казахстан башкаласында 25–27 сентябрь көннәрендә узa. Күргәзмә 12 мең кв. метрдан артык мәйданны били, биредә өстенлекле проектлар тәкъдим ителә. Үз экспозицияләре белән Россия һәм Казахстанның әйдәп баручы сәнәгать һәм инновацион компанияләре, шулай ук Белоруссия, Кыргызстан, Азәрбайҗан, Һиндстан, Иран, Пакъстан, Төркия һәм башка илләр дә катнаша.

◆Россия Хөкүмәте рәисе Михаил Мишустинга күргәзмә кысасында Татарстан белән Казахстанның уртак проектларын тәкъдим иттеләр. Республика стендында 40ка якын предприятие һәм югары уку йорты урын алган иде. Моннан тыш «Атом» электрокары проектын да күрсәткәннәр.

Нәтиҗәле җыен

20 меңләп катнашучы, 1 меңләп спикер, 100дән артык остаханә. Kazan Digital Forum – 2023 халыкара чарасына йомгак ясалды. Искәртеп үтик: быел ул беренче мәртәбә федераль статуста үтте. Быелгы форум нәрсәсе белән истә калды?

ӘҺӘМИЯТЕ. Татарстан башкаласында узган Kazan Digital Week – 2023 форумы төрле илләрдән килгән белгечләрнең замана технологияләре турында сөйләшү, фикер алышу һәм тәҗрибә уртаклашу мәйданчыгына әйләнде. Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин белдергәнчә, форумда математика, физика, ясалма интеллект һәм кибернетиканың төп законнарына нигезләнгән технологияләрне камилләштерү, арттыру турында сүз барды, яңалыкларга да урын булды.

– Форум ил компанияләренә һәм үз эшләнмәләрен күрсәтергә теләүчеләргә партнерлар, инвесторлар игътибарын җәлеп итәргә мөмкинлек бирде, – диде ул.

НӘТИҖӘ – САННАРДА. Меңәрләгән кеше алдында 900 спикер чыгыш ясады. Форум көннәрендә 107 секция һәм мастер-класс, форум партнерларыннан 5 конференция оештырылды, 34 «түгәрәк өстәл»дә фикер алышу узды. Форум көннәрендә күргәзмә эшләде. Биредә үз эшләре белән 133 компания катнашты. Иң мөһиме – форум кысасында 37 килешү имзаланды. Мисал өчен, шуларның берсе – барлык хакимият органнары бер бердәм оешмаларын Россиядә җитештерелгән операцион системага күчерү.

– Форум программасы бик әчтәлекле иде. Бу – бик файдалы чара. Биредә тәҗрибә алмашу бара. Бик кызу фикер алышулар, сессияләр узды, – дип бәяләде Казанда узган җыенны Россиянең цифрлаштыру министры Максут Шадаев.

Теманың дәвамы 3 нче биттә ›

ҮСЕШ АЧКЫЧЫ – ГАЛИМНӘРДӘ

Дәүләт Советында

Казанда Фән атнасы башланды. Спинлы (квант дөньясына хас термин) физика, химия һәм технологияләр өлкәсендә эшләүче, шулай ук үзләренең тикшеренүләрендә магнит резонансы ысулларыннан файдаланучы галимнәр өчен мөһим чараларның берсе бу. Анда катнашучыларны республика җитәкчелеге исеменнән Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Фәрит Мөхәммәтшин сәламләде.

– Фән атнасын Казанның электрон парамагнит резонансы фәнни мәктәбе – Россия Фәннәр академиясенең структур подразделениесе – Завойский исемендәге Казан физик-техник институты оештыруын билгеләп үтү күңелдә зур канәгатьлек хисләре уята, – диде Фәрит Мөхәммәтшин, форумда катнашучыларга мөрәҗәгать итеп.

Дәүләт Советы Рәисе, Президент Владимир Путин Указы нигезендә, Россиядә 2022–2031 елларның – Фән һәм технологияләр унъеллыгы, ә Татарстанда 2024 елның республика Рәисе тарафыннан Татарстанның фәнни-технологик үсеш елы буларак игълан ителүен искәртте. «Әлеге башлангычлы тормышка ашыруны бик мөһим эш дип саныйбыз һәм аңа барлык дәрәҗәләрдә ярдәм итәргә ниятлибез», – дип басым ясап әйтте ул.

Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренә караганда, республикада фәнни өлкәгә төрлечә ярдәм күрсәтелә. Болар – грантлар һәм стипендияләр, фәнни премияләр, конкурслар, корпоратив программалар. «Мондый чараларга һәр ел саен 20 миллиард сумнан артыграк акча җәлеп ителә – җитди сан! Шуның нәтиҗәсе буларак, республика федерация субъектларының фәнни-технологик үсеш рейтингында лидерлар бишлегенә керә. Бу – Татарстандагы 13 мең галимнең (шуның 60 проценты чамасы – яшьләр) саллы уңышы. Бүген залда яшьләрне – булачак галимнәрне күрү аеруча зур шатлык хисләре уята. Нәкъ менә аларның фәнни эшчәнлеге Татарстан икътисадын үстерүдә гаять зур роль уйный. Яшь галимнәрнең яңа ачышларының тиз генә тормышка ашырылачагына һәм предприятиеләребездә кулланылачагына ышанам. Бу безгә, җитди санкцияләргә карамастан, көндәшлеккә сәләтне югалтмаска ярдәм итәчәк. Икътисадыбыз нәкъ фәнни эшләнмәләр нигезендә яңа биеклеккә күтәрелер, дип уйлыйм», – дип билгеләп үтте Дәүләт Советы Рәисе.

Фән атнасы Казанда 25–30 сентябрьдә үткәрелә. Аның кысасында Евгений Завойский исемендәге Халыкара премия (1991 елда Татарстан Хөкүмәте ярдәмендә гамәлгә куелды) тапшырылачак, шулай ук кайбер халыкара конференцияләр үткәреләчәк. Һәрбер конференциядә кимендә 150 кешенең: Россия төбәкләреннән, Азия һәм Европа илләреннән килгән зур белгечләр, яшь галимнәрнең катнашуы көздә тотыла.

Үзем күрдем

УРМАН ТУЛЫ ЧҮП

Узган шимбәдә «Татарстанның чиста урманнары» акциясе башланды. Республикакүләм чистарту өмәсенә теләге булган барлык кешеләр кушылды. «ВТ» журналисты да Лаеш районының Матюшино урманчылыгында узган өмәдә катнашты.

Урманнарга керсәң, җырлап кермә, аяк астына карап, чүп-чарга шаккатып кер икән! Шимбә көнне урман суласын, яшәсен дип килүчеләр күп иде.

– Әлеге чара 2010 елдан бирле уздырыла. Елдан-ел катнашучылар саны арта. Өмәгә чыгучылар арасында яшьләр күп. Димәк, киләсе буын табигатьнең чисталыгына битараф түгел, – диде урман хуҗалыгы министры урынбасары Рәис Гомәров.

Табигатьне ярату күңелендә булырга тиеш, ди Казан авиация көллияте студенты Зилә Гыйльманова:

– 5 яшемнән әнием белән чистарту өмәләренә барам. Агач утыртуны да калдырмыйм. Казанның күп кенә урыннарында үз агачларым үсә. Кайвакыт аларны карап та кайткалыйм. Мине берәү дә мәҗбүр итми, үземнең катнашасым килә. Куплар, кем ташлаган шул җыйсын, ди. Җыяр булса, ташламыйлар иде аны. Шуңа күрә мин, булдыра алганча, урманга ярдәм итәм.

Казан шәһәр яны урманчылыгы җитәкчесе Илнур Кәшафиев әйтүенчә, урманны чүпләүчеләрне кулларыннан тоту мөмкин түгел диярлек.

– Урманнарга күбрәк төзелеш материаллары калдыкларын ташлыйлар. Без агач утыртабыз, тәрбиялибез, яңартабыз, чистартабыз. Ә кемдер китерә дә чүп ташлый, – ди ул.

Әле менә күптән түгел бер ай буена машинасы белән Столбище урманчылыгына калдык ташыган ир-атны тоткannар. Татарстан Урман хуҗалыгының дәүләт контроле һәм күзәтчелеге җитәкчесе Айрат Әхмәров сүзләренчә, тәртип бозучының эзенә төшү җиңел булмаган. Иң элек чүп ташланган урынга видеокамера куелган. Фотога төшереп алу җайланмасы да урнаштырылган. Урманчылар бу кешене тотар өчен кизү дә торган хәтта.

– Инде тоттык дигәндә генә, бу ират машинасын ташлап качты. Куркудан шулай эшләгәндер инде. Хәзерге вакытта ул кешегә 100 мең сум штраф салынды, табигатькә килгән зыянның күләмен билгелибез. Аннары ул шул сумманы да түләргә тиеш була, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА



mirleshoz.tatarstan.ru

САН

Көзге өмә **11** сентябрьдән **1** ноябрьгә кадәр дәвам итәчәк. Узган шимбәдә республикада яшәүче 15 мең кеше урманнарны чистартырга чыкты. Акция кысасында **1,5** кубометр каты көнкүреш калдыгы җыелды. Урман эченнән **0,5** кубометр чүп чыгарылды. **2,5** кубометр кипкән агач ботаклары өеммәргә өелде. Язгы чорда Татарстан урманнарыннан **700** кубометр каты көнкүреш калдыгы чыгарылып, **3** мең кубометр корыган ботаклар җыелган иде.

«ТУГАНЫГЫЗ АВЫР ХӘЛДӘ...»

ТАТАРСТАНДА МОШЕННИКЛАРДАН ЗЫЯН КҮРҮЧЕЛӘР САНЫ КИМЕМИ

Борчыган мәсьәлә

Бер тәүлектә – 7 млн сум! Татарстанда мошенниклар корбаннарының югалткан акчалары бу. Алдаганда яшеңә дә карамыйлар – алданучылар арасында яше дә, карты да бар. Кемне һәм күбесенчә ничек алдыйлар? Кырыгалдарлар тозагына ничек эләкмәскә?

Бер көндә – 11 кеше

Чаллыда яшәүче 84 яшьлек әбекәйгә телефон аша кайгылы хәбәр җиткерәләр: «Кызыгыз юл һәлакәтенә очраган, аны коткарыр өчен 140 мең сум акча кирәк». Аны-моны уйлап тормыйча, акчасын әзерли дә өенә үк килгән курьер кулына тоттырып җибәрә. Бары шуннан соң гына баласына шалтыратып, төп башына утыртуларын аңлый ул.

Мондый очраклар бихисап. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы да соңгы арада кырыгалдарларның аеруча активлашуы турында кисәтә. Министрлыкның рәсми сайтындагы мәгълүматларга караганда, бер тәүлек эчендә (22 сентябрьдә) телефон аша 11 кеше алданган. 20 яшьтән алып 84 яшькә кадәр булган 8 хатын-кыз һәм 3 ир-ат кырыгалдарлар кулына җәмгысы 7 млн сум акча тапшырган.

Иң киң таралган һәм мошенниклар яратып куллана торган алдау ысулы – «туганыгыз авыр хәлдә» дип хәбәр итү. Ни рәвешлерәк алдауларын Чаллыда яшәүче 84 яшьлек әби мисалында аңлаттык инде. Белгечләр әби-бабайларга аеруча сак булырга куша: мошенниклар бу ысул белән нәкъ менә өлкән яшьтәгеләрне алдарга ярата.

Моңа охшаган хәл Нурлатта да булган иде. 81 яшьлек бабай 400 мең сум акчасын 23 яшьлек курьерга тапшырган иде. Аңа исә: «Оныгыгыз юлда фаҗига китереп чыгарган. Аның җинаять җаваплылыгына тартылуын теләмәсәгез, акча түләгез», – дип шалтыраткан булганнар. Бабай, ике уйлап тормыйча, булган акчасын конвертка тутырган да яшь егеткә тапшырган. Ул егетне инде табарга һәм тоткарларга өлгергәннәр, әлеге очрак буенча җинаять эше кузгатылган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Банк картагыздан акча югалачак», «Сезнең исемгә кредит алмакчылар» ише сүзләр белән шалтыратулар да шактый икән. Әйтик, Казанда яшәүче 50 яшьлек ханым һәм Чаллыда яшәүче 53 яшьлек ханым мошенникларның нәкъ менә шушы ысулларына «кабып», 2 һәм 3 млн сум акчаларын югалткан.

Интернеттан ни дә булса сатып алганда да уяу булырга кирәк, ди белгечләр. 20 яшьлек Казан егете бер бушлай игъланнар сайтыннан автомобиль сатып алырга карар кылган. Сатучысы алдан 480 мең сум залог җибәрергә кушкан. Нәтиҗәдә яшь егет акчасыз да, «тимер ат»сыз да калган.

Яңалыклар

Болары классик, безгә күпмедер дәрәҗәдә таныш ысуллар булды. Ләкин кырыгалдарлар тик ятмый, күптән түгел яңа ысул уйлап тапканнар. Белгечләр аңлатуынча, мошенниклар, банк хезмәткәрләре исеменнән шалтыратып, телефонга диагностика үткәрергә һәм куркынычсызлык буенча махсус хезмәтләр рәсмиләштерергә тәкъдим итә. Шуннан соң кызыккан кешегә махсус сылтама җибәрәләр. Ул сылтамадагы сайтны банкның рәсми сайтыннан аеру кыен, ди белгечләр. Кырыгалдарлар шул сайттагы хезмәтләр арасыннан үзеңә кирәген телефонга урнаштырырга тәкъдим итә икән. Мәсәлән, үзләреннән үк, ягъни мошенниклардан саклану чаралары, телефон ремонтлау буенча сыйфатлы сервис һ.б. Кыскасы, бүгенге заманда бигрәк тә актуаль булган хезмәтләр. Ләкин теге яисә бу кушымтаны саклаган очракта, онлайн банк һәм хәтта телефонны контрольдә тоту мөмкинлеген югалту куркынычы бар.

САН

Россия Үзәк банкы тәкъдим иткән мәгълүматларга караганда, 2022 елда телефон аша алдаучылардан зыян күрүчеләрнең югалтулары **14,2** млрд сумга җиткән.

Нишләргә соң?

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы, янә бер кат алданмас өчен, һәм алданган очракта нәрсә эшләргә кирәклеген аңлаткан. Гади генә киңәшләр кебек тоелса да, күп очракта онытыла шул алар.

Беренчедән, якын кешегез турында теге яисә бу хәбәр җиткереп шалтыраталар икән, аның үзе белән сөйләшкәнче, берни дә эшләмәгез.

Икенчедән, таныш булмаган номердан килгән хәбәр һәм мәгълүматларны кат-кат тикшерегез.

Өченчедән, банк карталарыгыз һәм исәп-хисап счетларыгыз турындагы мәгълүматны таныш булмаган кешеләргә хәбәр итмәгез.

Дүртенчедән, таныш булмаган кешеләрнең исәп-хисап счетына акча күчермәгез.

Бишенчедән, өлкән яшьтәге туганнарыгызга, танышларыгызга кырыгалдарлар һәм аларның алдау ысуллары турында сөйләгез.

Алданган очракта, «02» яки «112» номерларына шалтыратып, полициягә хәбәр итегез.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Kazan Digital Week – 2023

САНЛАШКАН МАТБУГАТ

IT ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕ МЕДИА ӨЛКӘСЕНДӘ КУЛЛАНЫП БУЛАМЫ?

Сарымы, сорымы – матбугат сүзе кирәк. Укучысы, караучысы, тыңлаучысы бар бит. Замана белән бергә мәгълүматны кабул итү һәм тапшыру ысуллары үзгәрә. Медиа өлкәсенә IT мөмкинлекләрне файдаланмый чара юк. Аларны куллану тәҗрибәсе турында Kazan Digital Week халыкара форумы кысасында сөйләштеләр.

Иң элек Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге китергән саннарга күз салыйк.

Россиядә үзәк телевидениегә ышаныч 53 процентны тәшкил итә. Икенче урында – төбәк телевидениесе – 47 процент. Бер үк дәрәҗәдә ышаныч дәрәҗәсенә аналитика, яңалыклар сайтлары, рәсми сайтлар (35 процент) һәм «Телеграм» каналы (31 процент) ия. Һәр бишенче кеше төбәк (25 процент) һәм үзәк радионы (24 процент) тыңлый.

ru.freepik.com

Очрашу санлашуга бәйле булса да, мәгълүмат чараларына ышаныч, мәгълүматны тикшерү кебек мәңгелек сорауларга мөрәҗәгать итми кала алмадылар бу утырышта. Заманасы шул бит.

Россия Дәүләт Думасы депутаты, мәгълүмат сәясәте, мәгълүмати технологияләр һәм элемтәләр комитеты рәисе урынбасары, танылган журналист Евгений Попов фикеренчә, мәгълүмат куллану үзгәрде.

– Кешеләрнең мәгълүмат алу чыганаклары бихисап. Алар аша ялган, агитация һәм башка ысулларны кулланып, ниндидер идеологияне кертергә тырышырга мөмкиннәр, – ди ул.

Ышаныч димәктән. Евгений Попов АКШ мисалында халыкның медиаөлкәгә булган ышаныч дәрәҗәсенең никадәр булуын әйтте. Тикшерүләр китергән саннарга таянып, билгеле.

– АКШта иң ышанычлы дип... һава торышын күрсәтә торган каналны саныйлар. Аннан соң PBS каналы, BBC, – диде белгеч. Моннан тыш ышаныч тудыра торганнар рәтенә USA Today, TIME журналы, FOX News кебек мәгълүмат чаралары керә.

Әмма бернәрсәгә дә тулысынча ышанып бетеп булмый. Баксаң, халыкның мәгълүматка шикләнеп карау сыйфаты арткан икән. Евгений Попов сүзләре белән әйтсәк, бу бик яхшы. Ник дигәндә, халык мәгълүматны шундук кабул итмичә, кат-кат тикшерү, чагыштыру һәм анализлау юлын сайлый. «Һәрвакыт шикләнергә кирәк!» – дип киңәш тә бирде белгеч.

Һәр тармакка хас проблема медиа өлкәдә дә бар. Евгений Попов сүзләренчә, кадрлар мәсьәләсе хәзер кискен тора.

«Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе җитәкчесе Фирдүс Гыймалтдинов бу утырышта республикадагы, аерым алганда, үзләрендәге вазгыять турында сөйләде. Яхшы кадрлар кирәк дигән фикер аның чыгышында да яңгырады. Бу җәһәттән хезмәткәрләр әзерләү серен дә әйтте.

– Узган ел Казан дәүләт мәдәният институты белән хезмәттәшлек итә башладык. Алар телевидение өчен белгечләр – тавыш режиссеры, режиссер һәм операторлар әзерли, – диде Фирдүс Гыймалтдинов. Хәзер штатта институт бетереп чыккан 13 кеше бар икән. – Практикасыз гына оста булам димә. Бу – хәзерге тенденция. Без шуңа күрә дә аларны нинди технологияләр белән эш итү көткәнен күрсәтер өчен үзебезгә чакырабыз, күрсәтәбез.

Цифрлаштыру дигән юлга да басканнар. Фирдүс Гыймалтдинов искә төшергәнчә, 2014 елда алар аналог телевидениесеннән цифрлысына күчтеләр. Онлайн радиолары (мобиль кушымта белән. – **Авт.**) бар. Анысы 2020 елдан бирле эшли.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Халык кәефе

ШАТЛЫГЫ КҮБРӘК БУЛСЫН

Һәркемнең – үз сөенече, үз көенече. Кемдер мул уңыш алуына куана, алга таба максатлар куя, кемдер махсус хәрби операциягә озаткан газизеннән, өзелеп, хәбәр көтә.

Шәрифҗан МӘҮЛӘВИЕВ,
табиб (Сарман районы):
– 76 яшьтә булсам да, һаман да эшләвемне сорыйлар. Берничә тапкыр китәргә талпынып карадым, тик алыштырырга кеше юк, дип җибәрмиләр. Инде медицинага килүемә дә 57 ел бит. Сарман районының Александровская амбулаториясендә эшли башлаганга да шактый еллар узды. Бер егетне, минем урынга килер дип, укуга җибәрделәр. Әле ул укып кайтканчы да миңа 81 яшь булачак. Боларны ярым шаярып әйтәм инде, зарланырга яратмыйм. Алга карап эшләргә, авыруларны дәваларга кирәк. Әлегә көзге авырулар баш калкытмады, авыручылар күп дип әйтеп булмый. Үзем дә бераз ял алган идем. Балалар Казанга кунакка алып килде.

Ришат ХӘНӘФИЕВ,
авыл җирлеге башлыгы (Зур Кукмара авылы):
– Безнең авыл җирлеге спортка зур игътибар бирә. Районда авыл советлары арасында үткәрелгән ярышта берничә ел рәттән беренче урын алдык. Соңгы ике елда 300әр мең сум акча бирделәр. Аларга спорт инвентаре, формалар алдык. Бу атнада авыл урамнары арасында спартакиада башланачак. 15 команда тупланды. Җиңүчегә тәкә бирелә. Бу авылны бик берләштерә. Шушы егетләр бөтен җирдә ярдәм итә. Нинди генә эш булса да, аларга таянам. Тик соңгы елларда яшьләр мондый чараларда катнашырга бик атлыгып тормый. Башлыча 30–35 яшьтәгеләр һәм өлкәнрәкләр актив. Авылдан соң районга барабыз. Планнар да, максатлар да зурдан. Авылда бар шартларга туры килә торган стадион саласыбыз килә. Быел үзара салым акчасын да бераз арттырып булмас микән, дибез.

Ринат ГАЛИМҖАНОВ, бакчачы (Әтнә):
– Кәефем әйбәт. Минем өчен дә, гаиләм өчен дә бик уңышлы һәм күңелле мәшәкатьләргә бай җәй узды. Беренчедән, өйдә эш күп булды. Йортыбызның икенче катын күтәрдек. Мин инде озак еллар виноградның төрле сортларын үстерәм. Быел алар да бик мул уңыш бирде. Ничә ел үстереп, мондый уңышны күргәнем юк иде әле. Тәме дә бик тәмле, җимешләре дә эре булды. Һәм тиз арада сатып та бетерергә насыйп булды. Берсе дә әрәм булмады. Кешеләр чират торып алдылар. Моннан тыш, минем бит әле умарталарым да бар. Анысының табышы уртача булды. Артык күп түгел, шулай да, начар дип әйтү дөрес булмас иде. Гомумән алганда, зарланырга бер генә сәбәп тә юк. Башкаларга да шундый сөенечле мәшәкатьләр генә телим.

Фирия ГАРИПОВА,
активист (Тукай районы Биклән авылы):
– Без, авылдагы хатын-кызлар берләшеп, апрельдән бирле хәрби операциядәге егетләргә 75 маскировка челтәре үреп җибәрдек. Тагын бишесен әзерләп куйдык. Җәен бакчада, хуҗалыкта эш тыгыз вакытта да туктап торганыбыз булмады. Көннәр суытуга, шәмнәр әзерләргә керешәбез. Челтәрләрнең төсләре алышынып тора. Язын – бер, җәен – бер, кышын башка төстә үрәбез. Фабрикада эшләнгәннәр белән чагыштырганда, безнекеләрне дошман техникасы күрми, танымый, ди егетләр. Шуңа күрә ярдәмебез тигәнгә чын күңелдән куана-куана эшлибез. Ялга кайткач, ир-егетләр үзләре дә шәхсән килеп, рәхмәт сүзләрен җиткерә. Челтәр үрүче хатын-кызлар арасында да якыннары, балалары, оныклары, танышлары яу кырында булганнар бар. Гомумән алганда, утызга якын хатын-кыз йөри. Бернинди дә мәҗбүриләү юк, һәркайсы үз эшенә бик җаваплы карый. Челтәр үрү өчен акча белән халык булыша.

Илнур ИБРАҺИМОВ, эшмәкәр (Казан):
– Кәефләр әллә ни шәптән түгел. Казанда берничә чәчәк кибете бар иде. Икесен ябарга туры килде, чөнки ихтыяҗ кимеде, бәяләр, чыгымнар артты. Халык элек чәчәк бәйләмен күпләп, зур гөлләмәләр итеп алса, хәзер берничә данә генә сатып алу ягын карый. Бизнеста бервакытта да җиңел булмады. Бәяләр артып торганда эшләү тагын да авырлашты.

Лилия ШӘРИПОВА, укытучы (Апас районы):
– Мәктәптә башлангыч сыйныфлар укытам. Балаларыбыз белән сагынышканбыз, очрашуны көтеп алдык. Быел яңа мәктәпкә чакырганнар иде, иялэшкән коллективны калдырып китәсем килмәде. Күңелем дә тыныч түгел. Ирем узган елның декабрендә хәрби операциягә алынган иде. Җәйдән бирле хәбәре юк. «Хәбәрсез югалучылар» исемлегендә тора. Ни уйларга да белмибез. Ничек кенә авыр булса да, начар уйларны башыма кертергә теләмим. Балаларны да яхшыга өметләндерәм. Алар да көн саен әтиләрен сорый. Сабыр булырга тырышсак та, тормышымның бик авыр вакытлары.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге казанышлары өчен Татарстан Республикасының Әлмәт районы Колшәрип авылыннан унбер баланың ата-анасы **Федоров** Денис Александрович, **Федорова** Ирина Александровна **Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» медале** белән бүләкләнде.

***

Югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе, нәтиҗәле фәнни һәм педагогик эшчәнлеге өчен «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең беренче проректоры – уку-укыту эше буенча проректоры **Леонтьев** Александр Васильевичка **«Татарстан Республикасының атказанган югары мәктәп хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары **Задворнова** Галина Юрьевнага, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савиново районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесенең опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы **Митченкова** Ирина Анатольевнага, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш муниципаль районындагы «Кайгырту» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе социаль хезмәткәре **Ишморзина** Венера Әхмәтҗан кызына, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районындагы «Опека» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе социаль хезмәткәре **Мостафина** Галия Сабир кызына, «Җәлил картлар һәм инвалидлар интернат-йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе бухгалтеры **Рәхимова** Гөлшат Фоат кызына, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районындагы «Шәфкатьлелек» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең өйдә хезмәт күрсәтү бүлекчәсе социаль эш буенча белгече **Рәшитова** Зөлфия Зәки кызына, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге социаль түләүләрне оештыру идарәсе башлыгы **Прохорова** Эльвира Минхәйдәр кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Буа районы кулланучылар җәмгыяте кафесы пешекчесе **Җәләлова** Фирүзә Барый кызына, «ЕЛХОВО Әлмәт районы кулланучылар җәмгыяте» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Мотыйгуллина** Кәүсәрия Минсабир кызына, «Чаллы икмәге сәүдә йорты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте территориаль директоры **Шәйхетдинова** Наилә Марат кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Стрела» регби клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы коллективына, «Стрела» регби клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы тренеры Гари Ван Гинкел **Бота**га, «Стрела» регби клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры урынбасары **Хисамов** Альфред Рафикъ улына, «Стрела» регби клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы спортчы-инструкторлары: **Давудов** Мөхәммәд Хәйбулла улына, **Давыдов** Герман Денисовичка, **Казаликашвили** Николай Геннадиевичка **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыятенең Идел-Нократ банкы рәисе урынбасары – 8610 номерлы «Татарстан банкы» бүлекчәсе идарәчесе **Сәхбиев** Рушан Флюр улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «КАМАЗ-Автоспорт» коммерциячел булмаган партнерлыгы баш механигы хезмәтенең автомобиль йөртүчесе **Зыятдинов** Алмаз Имаметдин улы, «КАМАЗ-Автоспорт» коммерциячел булмаган партнерлыгы баш инженеры **Мизюкаев** Вячеслав Викторович; эстрада сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен «Мунча Ташы» татар эстрада театры артисты **Кәлимуллин** Әнфис Рафис улы; республикада музей эшен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры **Нургалиева** Розалия Миргалим кызы; югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен «Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры **Равилов** Рөстәм Хамәт улы; театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлекләре өчен «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе сәнгать җитәкчесенең труппа буенча ярдәмчесе **Сысоева** Лилия Петровна, «Әлмәт татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты **Фәйзуллина** Раушания Самат кызы; массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыятенең «Чаян» журналы редакциясе» филиалы мөхәррире **Хәмзин** Алмаз Наил улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты Икътисадый анализ идарәсе башлыгы урынбасары **Павлова** Мария Андреевнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Бүләк

«Энә дә – бүләк, дөя дә – бүләк», – дигән сүзне бүләк алучы уйлап чыгармаган. Бирүче уйлап тапкан аны. Эшлекле, бай һәм акыллы кеше. Ярлы бәндә үзенең соңгы дөясен бүләк итәргә мөмкин. Ә һәр тиенен чутлап тотарга күнеккән эшлекле адәм алай кыланмый. Ул аркылысын-буен исәпли дә үзенә файдалы якны карый, файда килерлек булмаса, намусы кушканча эшли.

Ләкин бүләкнең серле яклары күп. Менә ярлы, кадерсез бәндә сиңа дөя бүләк итсә дә, ул әллә ни булып күренми. Ну, биргән инде, бахыр, тырышкан, димәк, сине хөрмәт итә, бәлки, үзен әйбәт күрсәтергә тели. Ярый, бик маладис, рәхмәт. Бетте. Кыйммәтле бүләген алып куясың да теге кешене онытасың. Үзең шикеллерәк кеше бит инде ул, бәлки, чүт кенә түбәнрәктер дә әле, тиң түгелдер. Андыйларның хөрмәте дә, ихтирамы да, хәтта яратуы да артык сөендерә алмый. Үзеңнән түбәнрәк дәрәҗәдә дип уйлаган кешенең хис-тойгылары сиңа шәхеснең түгел, ә түбәнлекнең мөнәсәбәте кебек күренә.

Әгәр шул дөяне сиңа бик абруйлы кеше бүләк итсә, бу – бөтенләй бүтән. Сирәк кенә андый хәлләр дә була. Тик андый адәмнең дөя бүләк итүе дә мотлак түгел, аның хәтта энәсе дә зур вакыйга булып күренә. Әйтик, Билл Гейтс, юбилеегыз яки никахыгыз белән котлап, открытка җибәргән, ди. Алтмыш тиенлек катыргы кисәге. О-о-о, бу тарихи вакыйга булып тоела. Шуны күрсәтү белән, ә сез аны күрсәтми калмыйсыз, калалмыйсыз... Булмый алай... Мин-минлек рөхсәт итми... Шуны күрсәтү белән, табыныгызда утырган кунаклар чыш-пыш килә башлый, аларның күзләрендә ихтирам-хөрмәт арта, сез аларның күз алдында зураеп киткәндәй буласыз. Яки берәр зур җитәкче Почет грамотасы бирә. Мактау кәгазе. Президент бирә. Һәм шуннан да зуррак бүләк юктыр кебек тоела. Кешеләр өчен дә сез Президентның җан дусты, гомер буена аның белән шап та шоп кул бирешеп күрешеп йөргәндәй буласыз.

Бүләк бирүченең абруе никадәр зуррак, дәрәҗәсе ничек югарырак, бүләкнең дә кадере шултиклем була. Эш хәтта аның нәрсә бүләк итүендә дә түгел, эш аның бүләк итүендә дә түгел, эш аның сезгә игътибар бүлүендә. Бу игътибар бөтен гомерегез эчендә биш минут булырга мөмкин, бер минут, ике мизгел... Тик ул бар һәм шулкадәр кадерле. Аны үзегез дә кадерлисез, башкалар да хөрмәтли. Соклангыч мизгел!

Абруйлы затның сезгә игътибар күрсәтүе, бүләк бирүе – бернигә дә алыштыргысыз кадерле нәрсә. Абруе никадәр зур, кадере дә шулай. Бу бәхәссез.

Ләкин бүләкнең дә төрлесе була.

Менә сез сау-сәламәт, чир-чорларның нәрсә икәнен дә белмисез. Кешеләр саклана, сәламәт яшәү рәвеше алып бара, диеталар тота, спорт белән шөгыльләнә һәм барыбер авырый. Ә сезгә чуртым да булмый. Әлбәттә, яхшы кеше инде сез, чыдам, ныклы, көчле, булдыклы.

Яки мөлкәтегез ташып тора, нинди генә эшкә тотынсагыз да, кулыгыздан килә, уңышка ирешәсез, акчагыз гел артып тора. Әйбәт кеше инде сез, акыллы, булдыклы, тотанаклы, тырыш. Ә беләсезме, җирдә шундый кешеләр ничә данә? Белмисез. Алар күп, хәтта сездән дә булдыклыраклары бар, әмма алар сез ирешкән табышның яртысын да алалмый.

Иртән торасыз менә, күкрәк тутырып саф һава сулыйсыз, киерелеп аласыз, ә күктә кояш елмая, ягымлы җил исеп уза, кошлар сайрый, агачлар шыбырдаша, чәчәкләр нур сибә, хуш исләре тарала... Һәм боларның барысы да бушлай. Бүләк алар. Һәр көн, һәр мизгел бүләк.

Абруйлы, дәрәҗәле, танылган затларның һәр бүләге безгә зур булып, кадерле булып тоела. Без аларга чиксез рәхмәтле булабыз. Бу һәрвакыт шулай. Бер генә искәрмә бар.

Без Ходай биргән нәрсәләрне генә тиешенчә кадерли белмибез. Ни өчен? Белмим. Бәлки, аның котлау сүзләре әйтеп, тост күтәргәнен көтәбездер...

shutterstock.com

ТӘРБИЯЧЕ АЙСЫЛУ ЛОТФУЛЛИНА:

«КӨРӘШЕРГӘ ТҮГЕЛ, ФАЙДАЛАНЫРГА КИРӘК»

Горурлык

Төньяк Осетиянең Владикавказ шәһәрендә узган «Иң яхшы туган тел һәм әдәбият укытучысы – 2023» бөтенроссия конкурсының тәрбиячеләргә кагылышлы номинациясендә Казанның 41 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Айсылу ЛОТФУЛЛИНА җиңү яулады. Аның белән бәйге, шәһәр балаларын туган телгә өйрәтү нечкәлекләре турында сөйләштек.

Айсылу Лотфуллинаның шәхси архивыннан

:: Айсылу, илкүләм бәйге нинди тәэсир калдырды?

– Дәресләрне Владикавказдагы бакчаларның берсендә үткәрдем. Анда дәүләт телләре – осетин һәм рус теле. Дәресемне русча алып бардым, туган телгә хөрмәт уятырга тырыштым. Осетиннарда ватанпәрвәрлек хисе көчле. Үз илләрен хөрмәт итәләр, телләрен яхшы беләләр.

:: Үзегез кайсы яктан? Ни өчен нәкъ менә туган тел укытучысы белгечлеген сайладыгыз?

– Арча районы Яңа Кенәр авылыннан, миңа – 34 яшь. Педагогик стажым – 12 ел. Казандагы 41 нче мәктәпнең балалар бакчасында татар теле дәресләрен алып барам. Туган телемне, балаларны яратканга укытучы һөнәрен сайладым. Монда татар теле укытучысы Гөлнар Гайнуллинаның өлеше зур. Аннан минем әти-әнием дә – тәрбияче. Алар 40 елга якын Яңа Кенәр интернат-мәктәбендә эшләде, хәзер инде лаеклы ялда. Югары уку йортының инглиз-татар теле юнәлешен тәмамласам да, мине татар теле үзенә күбрәк тартты. Сабыйлар дөньясында булу аеруча рәхәтлек бирә.

:: Шәһәр баласына татар телен өйрәтү җиңел түгел. Аларны ничек кызыксындырасыз?

– Иң мөһиме – татар телендә сөйләшергә теләк уяту. Замана баласының ихтыяҗыннан чыгып эш итәргә тырышам. Аларның дөньясында яшим. Нәрсә карый, укый, кем өчен җан ата? Шуңа игътибар итәм. Әгәр сабыйларга кызык түгел икән, нинди генә алымнар кулланса да, нәтиҗә булмаячак.

Замана баласына хәзер «клиплы» фикер йөртү хас. Сәбәбе – телефон, социаль челтәрләрнең йогынтысы зур булу. Кая гына карама, рекламамы, башкасымы – барысы да кыскача мәгълүмат алуга юнәлдерелгән. Мин, күрсәтмә модельләштерү алымына нигезләнеп, «Рәсемле сүзләр» дип аталган дидактик кулланма булдырдым. Сүзләр беркетелгән рәсемнәр ярдәмендә 3–7 яшьлек балаларны сөйләшергә өйрәтәм. Хәрәкәтләр, куллар белән дә күрсәтеп була моны. Күнегүләр ясатканда да, урамга саф һава суларга чыккач та кулланам. Балаларга татар телен истә калдыру өчен отышлы алым бу. Шәһәр баласы русча уйлый, сөйләшкәндә фигыльне алга куя. Мин аларны дөрес сөйләшергә өйрәтәм. Бәйгенең мастер-классын да шушы алымга карап төзедем.

Балаларда телгә кызыксыну артуны сизәм. Алар шатланып: «Ура, татар теле була!» – дисә, миңа рәхәт. Күзләрендә очкын күренмәсә, әһә, авыррак, аңлап бетермиләр, җиңеләйтергә кирәк, дип үзгәртәм. Баштарак исемемне истә калдыра алмаганнар мине «Татарский» дип йөртә иде.

Әти-әниләрнең татар теленә мөнәсәбәте яхшы. Мәктәпкә кергән балаларның әти-әниләре белән дә аралашып торабыз. Балалар бакчадан кирәкле белемне алып чыга. Әти-әниләр өйдә татарча ешрак аралашсын иде.

:: Айсылу, «клиплы» фикер йөртү дигәнең укучыларга да, җәмгыятькә дә кагыла. Моңа каршы көрәшергә кирәкме?

– Бу сорауны миңа бик еш бирәләр. Көрәшергә мөмкин. Балалар белән күбрәк урамда йөрергә, бергә әкиятләр укырга... Кыскасы, алымнар бар. Әмма көрәшеп отачакбызмы? Без замана баласының мәнфәгатьләрен кайгыртырга тиеш, дип уйлыйм. Әгәр аларның ихтыяҗын исәпкә алмыйбыз икән, берничек тә кызыклы була алмыйбыз. Шуңа күрә көрәшергә түгел, эшебездә файдаланырга кирәк.

:: Туган тел укытучысының, тәрбиячесенең абруе артамы?

– Ихтыяҗ булса, абруй булачак, дип уйлыйм. Конкурслар, чаралар ешрак үткәрелсә, ихтыяҗ да булачак, телнең абруе да үсәчәк. Дәүләтебез бу өлкәдә – дөрес юлда. Бик күп чаралар, бәйгеләр үткәрелә, грантлар игълан ителә. Татар телендә балалар каналлары, электрон китапханәләр, сайтлар актив эшләп килә. 2023 елның «Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы» дип игълан ителүе дә очраклы түгел, ә дәүләтебезнең максатчан оештырылган чарасы. Бу мине бик шатландыра.

Сәрия МИФТАХОВА



БУЛАЧАК КОСМОНАВТЛАР – АРАБЫЗДА

Очрашу

Татарстаннан космонавт бар, ул – Сергей Рыжиков, ә менә татарлар арасыннан әлегә юк. Казанның 171 нче мәктәбенә «Җиһангирлар марафоны» ачылышына җыелган укучыларны беренче чиратта шушы мәгълүмат уйга калдырды бугай. Җитмәсә, булачак космонавтлар – сезнең арада, дип әйтеп торалар бит. Шулай булыр кебек тә ул. Балалар бик кызыксындылар. Рәсми өлештән соң кунакларны сораулар белән күмеп ташладылар.

Бигрәк тә Казан шәһәренең шәрәфле гражданины, физика-математика фәннәре докторы Урал абыйлары Закировка «эләкте». Космос өлкәсенә бөтен гомерен багышлаган 84 яшьлек абыйлары сынатмады. Һәр сорауга егетләрчә җавап биреп кенә торды. Аның белмәгән нәрсәсе сирәктер. Кайчандыр беренче космонавтлар әзерләү отрядында шөгыльләнгән, сәламәтлеге какшау сәбәпле китәргә мәҗбүр булган. Байконурда космик аппаратларны галәмгә җибәрү – аның озак елларга сузылган төп эше. Бу гамәлләре белән бүген дә горурлана.

«Җиһангирлар» хәрәкәтен башлап җибәргән Хәлил Гайнетдиновның да эшләре туры юлдан бара дип уйлыйк. Арча педагогия көллиятендә һәм мәктәпләрендә башланган хәрәкәт җайлы гына «тәгәрәп китте» булса кирәк. Бүген инде Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы да укучылар арасыннан космонавтлар үсеп чыгуына инана кебек. Министрлыкның милли эшләр бүлеген җитәкләүче Илдар Халиковның тел төбеннән шулай сизелә. Марафонны оештыру эшләрен үз канаты астына алулары да шул хакта сөйли.

– Быел без бу хәрәкәтне оештырып җибәрү өчен штаб итеп Казандагы берничә мәктәпне билгеләдек. Алар төрле районнарда урнашкан. Соңрак республикадагы һәр мәктәпне җәлеп итәргә исәплибез, – диде Илдар Илгизович.

Форсаттан файдаланып, балачагын да искә төшереп алды. Чыннан да, ул вакытта нинди генә малай космонавт булырга хыялланмаган икән.

– Әле студент елларында да мин: «Галәмдә ниләр бар икән?» – дип уйлана идем. Ниндидер омтылыш гел еракка, офыклар артына өндәде. Әмма, ни кызганыч, сиксәненче елларда өметләр сүрелде һәм сүнде. Галәм белән кызыксыну, гомумән, ил күләмендә юкка чыкты. Сез бәхетле: хыялларыгызны тормышка ашыра аласыз. Хәзер космос өлкәсендә яңа чор башланды.

Старт көнен оештыру эшләрен үз өстенә алган 171 нче мәктәп директоры Рания Галиәкбәрова да шундый фикердә.

– «Җиһангирлар» инициатив төркеме җитәкчесе узган уку елының апрель аенда очрашуга килгән иде. Укучыларның кызыксынуына чик-чама булмады. Шуннан ничектер бер җепкә башка чаралар да бәйләнеп китте. Башта Арча районындагы Җиһангирлар паркы төзеләчәк Кенәр авылына юл тоттык. Космонавт Сергей Рыжиков Казанга килгән иде, IT паркта бик кызыклы очрашу үткәрде. Балалар сорауларны яудырдылар гына. Сокланырлык та, гаҗәпләнерлек тә иде бу күренеш. Шул чакта, укучылар галәм турындагы яңалыкларга бик сусаган икән, дигән фикергә килдем, – диде ул.

Автор фотосы

– Россия Президенты Владимир Путин, Ростов кызы Маша Андреева белән очрашып, аның космоска кагылышлы эшләренә зур бәя биргәннән соң, безнең балаларда да ниндидер бер ашкыну барлыкка килде. Форсаттан файдаланып, шунысын да әйтик: Арча мәктәбендә укучы балалар инде 2015 елда ук «Мәгариф өлкәсендә – минем инновацияләрем» дигән федераль бәйгедә җиңеп чыкканнар иде. Ул проект «Җиһан – гагаринчылар иле» дип атала. Андагы тәкъдимнәрне мәктәпләрдә бүген дә кулланырга уйлыйбыз, – дип, Хәлил Гайнетдинов бу стартның бик урынлы һәм вакытлы алынуын әйтте.

«Кем иң беренче татар космонавты булырга тели? Сезгә бу мөмкинлек бирелгән», – дигәч, кызларның да, малайларның да күзләрендә очкын кабынды. Әмма Хәлил абыйлары беренче чиратта тарихны белергә кирәклеген дә искәртте. Чөнки космос өлкәсендә Татарстанның да, татарларның да эшләгән гамәлләре бәяләп бетермәслек. Бүген дә милләттәшләребез алгы сафта. «Шундый милләтнең үз космонавты булмау күңелне кырып тора. Сез бу бушлыкны тутырырсыз дип ышанам», – дип өметләр баглады.

Әйтергә кирәк, Җиһангирлар марафонының программасы бик бай. Эшләр башланды да инде. Чөнки сентябрьдә Казанда яшәп, ракета двигательләрен ясаучы Сергей Глушконың тууына 115 ел булды. Космонавтиканың «атасы» Константин Циолковский да шушы айда дөньяга килгән. Ә октябрьдә галәмгә беренче иярченне очырганнар. Ноябрьдә «Энергия-Буран» проектын тормышка ашыруга 35 ел була... Шулай итеп, җирдәге тормыш галәмнән аерылгысыз булып чыга. Димәк, Хәлил Шәйхнуровичның: «Без җир кешеләре генә түгел, галәм кешеләре дә, ягъни җиһангирлар», – дигән сүзләре бик дөреслеккә туры килә.

Ә марафонга нәтиҗәне, зур фестиваль оештырып, 2024 елның 12 апрелендә, ягъни беренче космонавтыбыз Юрий Гагарин галәмгә юл алган көндә ясарга уйлыйлар.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ХАЛЫКАРА «ТАТАР КЫЗЫ» БӘЙГЕСЕ ҖИҢҮЧЕСЕ АЛЬБИНА МЕДВЕДЕВА:

«ӘНИЕМНЕҢ ТЕЛӘГЕ ТОРМЫШЫМНЫ ҮЗГӘРТТЕ»

vk.com/tatarkizi_official

Альбина турында белешмә

- 23 яшь.
- Уку урыны: Пенза дәүләт университеты (тел белгече).
- Эш урыны: «Россия 1 – Пенза» дәүләт телерадиокомпаниясендә алып баручы.
- 11 яшькә кадәр бал һәм спорт биюләре белән шөгыльләнгән, әдәбият һәм психология белән кызыксына, татар халык ашларын пешерергә ярата, буш вакытларында модель, стилист-визажист булып эшли.

Пенза кызы Альбина МЕДВЕДЕВАның «йолдызлы сәгате». Ул Үзбәкстанның Ташкент шәһәрендә узган Халыкара «Татар кызы» бәйгесендә җиңү яулады. Татарның «каймагы» яши торган Пенза өлкәсендә туып-үскән кыз бүген нинди уй-хыяллар белән яши? Бәйгедән соң ниләр кичерә? Без әнә шуны белештек.

:: Альбина, дөнья күләмендә «Татар кызы – 2023» булып танылдың. Ниләр кичерәсең?

– Җиңүемә ышанып бетмим әле. Зур шатлык, горурлык хисләре кичерәм. Мине һаман да котлыйлар. Көн саен дусларым, туганнарым һәм хәтта таныш булмаган кешеләр яза, бөтен Пенза өлкәсе минем белән! Бу миңа ышаныч һәм көч бирә. Минем өчен халыкара дәрәҗәдәге титулны безнең Пенза ягына китерү – зур хөрмәт һәм җаваплылык. Барысы да шундый тиз үтте, әкияттә сыман булды. Тормышымның бу этабы турында хатирәләр әле озак вакыт күңелемне җылытыр.

:: Финалга үткәч, «җиңәм» дигән уй белән яндыңмы?

– Җиңәргә дигән төгәл максатым юк иде. Минем өчен иң мөһиме – бу проектта алган тәҗрибә һәм белем. «Татар кызы» бәйгесе яңа мөмкинлекләр, юллар ача. Кызлар белән дуслашып, бер-беребезгә ияләшеп беттек, зур эш башкарып чыктык. Дөресен генә әйткәндә, минем «Татар кызы»нда катнашу хыялы да юк иде. Бу – әниемнең теләге. Бүген исә бәйге тормышымны һәм киләчәккә планнарымны нык үзгәртте.

:: Халыкара «Татар кызы» титулын алу яңа мөмкинлекләр бирү белән беррәттән зур җаваплылык та йөкли. Син моны тоясыңмы?

– Әлбәттә. Хәзер мин безнең төбәк тарихында эз калдырырга телим. Татар мәдәнияте өчен файдалы нәрсәләр эшләргә телим. Бәлки, бу татар кызлары өчен проект булыр, аларга үз талантларын үстерергә ярдәм итәр.

:: Әлеге бәйгедә «Чын татар кызы нинди булырга тиеш?» дигән сорауга җавап табып булдымы? Үзеңнең фикерең нинди?

– Әлеге сорауга җавап бирү кыен. Без барыбыз да төрле. Иң мөһиме – игелекле һәм ачык күңелле булу. Ихлас, максатчан, акыллы һәм эшчән. Эчке матурлыгың булмаса, тышкы матурлыкның кыйммәте юк.

:: Синеңчә, татар мәдәниятен һәм телен саклау өчен нәрсә эшләргә кирәк?

– Беренче чиратта эшне үзебездән башларга кирәк. Мин татар мәктәпләрендә укымадым, татар дусларым аз иде, әмма безнең гаиләдә гореф-гадәтләрне хөрмәт итәләр. Өйдә татар телендә генә сөйләшәбез. Бәйрәмнәрдә, ял көннәрендә үзебезнең милли ризыкларны пешерәбез. Мәдәнияткә, туган телгә мәхәббәтне балачактан ук тәрбияләргә кирәк дип саныйм. Бәйге дә миңа татарлыгымны үстерергә ярдәм итте. Минем күңелем, көчем – туган телемдә, туган җиремдә, халкымда. Татар кызы булуым белән бик горурланам.

:: Кумирың бармы?

– Минем идеал – әнием. Минем өчен ул – матурлык һәм акыллылык эталоны, игелекле йөрәк. Ул – минем иң якын дустым, героем һәм кумирым. Иң зур хыялым – әти-әниемнең озын һәм бәхетле гомер кичерүе. Алар бәхетле булса, мин дә дөньяда иң бәхетле кеше булырмын. Гаиләмне дөнья тирәли сәяхәткә дә алып барырга телим.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

АШЫГАБЫЗ ДА АШЫГАБЫЗ

Беркөн көтү каршына миңа ияреп чыккан мәче баласын машина бәрде. Искитмәле матур, бик иркә, әле бер генә яшьлек булса да, инде күпне күргән (биялэй кадәрле чагында урман бете кадалган иде, аннан сыер басып, ярты санын өстерәп йөрде, быел яңагын нәрсәдер чагыпмы, шешеп, үлекләп, тишелде – без исә бөтен очракта да дәваларга, ярдәм итәргә тырыштык), соңгы җәрәхәте төзәлеп кенә беткән иде… Юлның каршы ягында торганда, әллә машинадан курыкты, юл читеннән «ГАЗик» белән узышып чаба башлады. Ул да чаба, машина да тизлеген киметми. Безнең капка турысына җитүгә, песи баласы өй ягына сикерде. Чыгып җитте дип уйлаган идек, әмма машина тәгәрмәче арткы өлешенә бәргән булып чыкты. Ике көн ул тилмерде, ике көн авыртуын киметергә тырышып без тилмердек… Һәм ике көн буе шофер ирне сүктем: яшүсмер егет булса, яшьлеккә сылтар идек, пенсия яшенә җитеп килүче кеше, өстәвенә күрде бит, күрмәсә, бер хәл иде, дим. Шул акылсыз песи баласы белән акылсызланып узышканчы, бер-ике секундка туктаганнан ни булыр иде дә… Юк шул, туктамады. Ә песиебез бер югалганнан соң өстерәлеп кайтып күренде дә кабат юкка чыкты. Һаман да җәлли-җәлли көтәбез үзен. «Бу юлы да терелсә, чын могҗиза булыр иде», – дип көтәбез.

Төп сүзем песиләр турында түгел иде. Ашыгып-кабаланып гомер кичерүебез турында уйланырга бер сәбәп кенә булды ул. Бигрәк кызу чорда яшибез. Һәм ул көннән-көн ныграк кызулана. Әйтерсең, Җир шары көннән-көн кызуырак әйләнә! Игътибар итсәң, бар дөнья ашыга: кешеләре дә, табигате дә, җан ияләре дә. Кемне карама, кайчан карама, ашыгуда. Һәм… һаман вакыт юклыктан зарлануда. Анда чаба, монда чаба кеше дигәнең – барыбер бернигә дә җитешми. Әти-әниләрнең, туганнарның хәлен белергә дә, гаилә белән табигать кочагына чыгып хозурланырга да, балалар белән шөгыльләнергә… тагын бик күп нәрсәләргә күпләрнең вакыты җитми. Студент елларда имтиханга әзерләнергә бер көн җитми калган кебек, адәм баласына гомер буе нәрсәнедер эшләргә һәрчак аз гына вакыт җитми кала… Кызганычка, әнә шул аз гына вакыт дигәнең зур үкенечләргә әйләнә дә. Ашыгып үткәргән гомерләр дә еш кына шуңа сәбәпче була. Ә без әле ул турыда уйланмыйбыз, ашыга бирәбез.

Юлга чыксаң, машиналар бер-берсенә дә, җәяүлеләргә дә юл бирми, ашыга. Кычкырталар, кагыйдә бозалар, тизлек арттыралар. Нәтиҗәсе еш кына бик аяныч. Кибет-даруханәләргә керсәң, синнән алда ике-өч кеше булса, инде эчкә «корт» керә: үтәме бу чират?! Хастаханәләрдә дә беркемнең дә чират торасы килми. Шул ук вакытта үзен чиратсыз кертүче булса, сөенә-сөенә керсә дә, чиратсыз керүчене яманлый, гаделлек-тәртип дигәне исенә төшә. Иртә булса, кичне көтәбез, кыш булса, язны дигәндәй… Шөкер, бу көн дә үтте, дип сөенә-сөенә, куа-куа гомерне үткәрәбез (шөкерне әйтә белсәк, ярый әле ул, еш кына анысы да онытыла).

Балаларның тизрәк үсәсе, укучыларның тизрәк мәктәп тәмамлыйсы, студентларның тизрәк диплом аласы килә (бу «тизрәк» дигәнең безгә сабый чактан салынган, ахры)… Әлеге баскычларны үткәч, ничектер рәхәт, җайлы булыр кебек тоела. Тик аларны үткәч, алга таба инде шуларның барысын сагына башлый: ул чакта бик рәхәт булган икән, ди. Әмма ул «рәхәтлек»кә инде юл ябык. Адәм баласы тагын күңеле белән ашыга, алга чаба башлый. Баш-аягы белән эшкә чумган чорда инде аңа пенсиядә бик рәхәт булыр кебек тоела, тик яшь чакта әллә кайда – Каф тавы артында булып тоелган картлык килеп җиткәч кенә гомере нигәдер бик тиз үткәндәй тоела. Хәер, арада башкача уйлаучылар да бар үзе. «Миңа элек пенсиягә чыгу үләргә вакыт җиту кебек тоела иде, әмма пенсиягә чыккач, яшең турында бөтенләй уйламыйсың икән, дөрестән дә, гомернең иң рәхәт чоры икән ул», – ди бер танышым. Тик бу чор рәхәт чакка әйләнсен өчен, килешәсездер, шактый сорауларга җаваплар әзер, чишелешләр табылган булырга тиештер.

Ашыгып яшәүләр, дөнья куулар да үзенекен итәдер: «төп йорт»ка китүче яшьләр дә көннән-көн арта. Кемдер йокыдан уянмаган, кем егылып үлгән… Анда барырга да ашыгабыз бугай…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

РИВАЯТЬКӘ – ҺӘЙКӘЛ

Чирмешән районындагы Туймәт авылы әрәмәлегендә тарихи каберлек бар. Анда 1920 елда булган «Сәнәк сугышы» корбаннары күмелгән. «Бу – әкият түгел, чынбарлык», – ди Ильяс хәзрәт Әһлиуллин. Туймәтлеләр әлеге урынга килеп, мәрхүмнәр рухына дога кыла хәзер.

Каберлек авылдан ерак түгел. Җирлек башлыгы Айдар Кәримов әйтүенчә, моңа кадәр анда таш кына торса, хәзер тарихи урынга әйләнгән. Әрәмәлек ярындагы каберлеккә чардуган һәм истәлек тактасы куйганнар. Сукмак салып, тотынып төшү өчен култыкса да ясаганнар. Мәрмәр тактаны Әкъдәс Гыйматдинов, чардуганны иганәче Рамил Кәримов эшләткән. Ильяс хәзрәт тәкъдимен җиткерү белән, бу эшкә олы яшьтәгеләр генә түгел, авыл яшьләре дә кушылган.

Моңа кадәр авыл халкы сигез кыз язмышын риваять буларак кабул иткән. Каберлек турында ишетсәләр дә, төгәл урынын белмәгәннәр. Ильяс хәзрәт Әһлиуллин исә моның чынбарлык икәнлеген исбатларга тырышкан. «Туймәтем – туган ягым» китабында да 1920 елның февралендә булган вакыйга турында кыска гына мәгълүмат бар. Әлеге гыйбрәтле хәлне элек әби-бабайлар еш телгә алган. Тик бу кабергә күмелүчеләрнең төгәл кемнәр икәнен белүче юк. Ильяс хәзрәт хәзер үзе дә 90 яшькә җитеп килә инде. Әтисе – сугышта, әнисе сугышка кадәр дөнья куйган. Ятимнәр йортыннан 3–4 нче сыйныфта укыганда кайткан малай. Өлкәннәрнең канлы вакыйга турында сөйләвен яхшы хәтерли ул. Яңгыр сорап, туймәтлеләр шунда «Карга боткасы» пешергән. Авылда 33 ел имам вазыйфасын башкарган Ильяс хәзрәт. Шушы вакыт эчендә мәрхүмә сигез кыз авылдашларының төшләренә бер генә мәртәбә кереп йөдәтмәгән. Әрәмәдә кызлар матур яулыклар бәйләп, милли алъяпкычлар ябып, әйлән-бәйлән уйнаган. Күбрәк шушы төш кергән икән. «Бабай, шул кызлар рухына дога кыл әле», – дип үтенгән авылдашлары. Хәзер җаннары тынычланган, күрәсең. Бу канлы вакыйганың 100 еллыгына авыл халкы алар истәлегенә корбан чалган.

– 1920 елның февралендә Бәркәтә авылында «Сәнәкчеләр фетнәсе» күтәрелә. Алар Туймәт авылына да килә. 17 яше дә тулмаган укытучы кыз һәм аның 7 укучысы аларның корбанына әйләнә. Фетнәчеләр, динне бетереп, рус әлифбасын өйрәтәләр дигән сылтау табып, кызларны мәсхәрәләп үтерәләр, – дип сөйли Ильяс хәзрәт.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Авыл халкы да, яшьләр дә хәзер әлеге урынны белеп тора», – ди җирлек башлыгы Айдар Кәримов.

Хәзрәт әйтүенчә, укытучы кызны авыл зиратына күмәргә рөхсәт итмиләр. Тәнен юк итәргә, үләт базына ыргытырга кушкач, авыл кешеләре мөгаллимәне төнлә елга буена күмә. Башка кызларны исә зиратта җирлиләр. Укытучының кабере җуелмасын өчен таш белән тамгалыйлар.

– Ул каберлек елга буендагы чокырда урнашкан. Мин үлсәм, аны күрсәтүче калмас дип борчылдым. Теләгемне иганәче Рамилгә җиткердем. Ул борчылмаска кушты. Чардуган корып буядылар. Мин барып дога кылдым. Тирә-ягы тәртипкә китерелгәч, тынычландым, – ди хәзрәт.

Сәрия МИФТАХОВА

Авыл җаны

«Мөмкин булмаган эш юк»

Бай тарихлы, заманында зур базарлы авыл бу. Ундүртенче гасырларга җитеп, бәкләр нәселенә барып тоташкан шәҗәрәле авыл. Күренекле тарихчы-язучыны биргән авыл. Мин аның бер гап-гади кешесе белән аралашып алдым.



Алар күмәк хуҗалык булып яшәп яталар икән. «Ничек инвестор кермәде сезнең якларга?» – дигән соравыма: «Безнекенең эсвәзләре зур; соңгы вакытта инвесторга бирү турында сүзләр йөри әле шулай да, җыелыш та уздырдылар, халык каршы инде каршылыкка. Алай да «безнеке» китсә, күршедәге агрофирмага бирәчәкләр дип торалар», – дип җавап бирде.

Башлыча игенчелек белән терлекчелек биредә. Элек орлык сатканнар.

– Хәзер ашлык сатып бик мантып булмагач, күбрәк терлекчелеккә күчте. («Күчтек, эшлибез» дип сөйләшми әңгәмәдәшем, димәк, бу җирдә үзен дә хуҗа дип санамый.)

– Фермалар әйбәт хәлдә безнең, саварга роботлар алды. Булган ашлыкны терлеккә ашатып, шулай азрак файда күрә иде инде. Сөтнең бәясе тагын төшеп бетте бит менә, шуңа акчасын да түли алмый. Авыл хуҗалыгы ул болай да көчкә-көчкә бара торган арба бит инде. Итне дә очсызга гына алып китәләр. Башкалар белән чагыштырганда, әйбәт бара инде ул үзе, түләү ягына гына кысмыр. Якын-тирә авылларда безнекеннән көчсезрәк хуҗалыкларда да түләү әйбәтрәк. Безнеке шул егерме меңгә дә җитми инде.

Техника ягы әйбәт. Кризисларга кадәр бик күп техника алып калган иде безнеке. Элемтәләре күп бит. Эшләргә кешесе генә юк. Бер кешегә дүрт-биш трактор, бер комбайн туры килә. Түләү бәләкәй булгач, кеше качып бетте.

«Кайбер якларда чит кавем кешеләре күбәйгән, сездә ничек?» – дим.

Элек әрмәннәр күп булган икән; түләү ягы начарайгач, китеп беткәннәр. Хәзер Мөслим ягыннан килеп эшләүчеләр бар икән. «Инвесторлар таратып бетергән авыллардан килеп эшлиләр».

– Гараж совет заманыныкы. Алай зарланырлык түгел дә, кыш көне кыенрак: суык, җылы кертелмәгән. Теләсә каян иске-москы утын табып, калай мичкә ягып маташалар инде малайлар (ул шулай дип сөйләшә – «малайлар» дип). Ярты көн утын ягып та, ул олы гаражны җылыта аласыңмы әле? Икенче көнгә тагын суынып бетә. Суыкта ачкычлар тотып эшләргә кирәк бит әле.

– Яшь гаиләләр унлап җыела микән? Эштә биш-алты күренә бугай.

Үзенә килгәндә… «Авылда әти-әнине карарга дип калдым мин. Төпчек буларак. Алар инде кайтмаска китте, хәзер инде без картаябыз. Чыгып китәргә дә соң кебек. Шулай да андый уйлар килгәли».

Яше иллегә якынлашып бара «картаябыз» диюче әңгәмәдәшемнең. Гаилә тормышы барып чыкмаган, ялгыз гына гомер көтә.

Буш вакытын табигатьтә үткәрергә тырыша. Спорт белән шөгыльләнә. Китап укый. Соңгы укыган китабы – «Валет пиковый». Совет чорындагы куштанлык, властька омтылу, коррупция турында. Фәнни-популяр китаплар укырга ярата, трансерфинг, квант физикасы кебек темалардан хәбәрдар. Борчуы да көндәлек мәшәкатьләр, матди проблемаларга бәйле түгел аның: «Шундый бөек халыкның киләчәген шушы хәлдә күрү авыр», – ди.

Ирләргә бик үк хас булмаганча (бәлки, ялгышамдыр) рәссам күзләре белән карый икән дөньяга: «Дөнья матур бит ул, күрә белсәң… Саф һавасы, назлы җиле. Кояшы. Кары, яңгыры… Бал кортлары… Санап бетермәле түгел…»

Матурлык күрергә теләгән күзләр авыл чынбарлыгының кайбер яклары белән очраша да тагын төшенкелеккә бирелә бугай. «Бүгенге авыл кешеләре – картлар да эчүчелек тозагындагы яшьләр. Буш урамнар. Показуха күп».

Бу сөйләшүдә мине иң гаҗәпләндергәне эчүчелек булды. Безнең авылда андый чир совет чоры белән чагыштырганда күпкә азайды, күзгә күренеп азайды. Ярты ай айный алмыйча эшкә чыга алмаган яки көн саен исерек булган ирләр (әңгәмәдәшем шулай ди, «айнык кеше юк диярлек, кеше өчен дә эшләп ялыктым») минем өчен үткәндә калган кебек иде. Әллә күмәк хуҗалык белән бергә бу чирнең дә булуы табигыймы соң?

Шулай да «виртуаль авылдашым» өмет белән яши. «Кеше иртәме-соңмы шуны аңларга тиеш: үзең тотынып үзгәртмәсәң, безнең өчен берәү дә килеп эшләмәячәк, мөмкин булмаган эш юк», – ди ул.

Лилия ФӘТТАХОВА

ИЛГИЗ ЗӘЙНИЕВ: «УЕН – БЕЗНЕҢ ТАБИГАТЕБЕЗДӘ»

«Әкият» театрының матбугат хезмәте

Галиәсгар Камалның «Беренче театры» белән «Банкрот»ын укымаган, карамаган татар юктыр ул. Тиздән бу ике мәңгелек комедияне курчаклар да куячак. «Әкият» курчак театрының баш режиссеры Илгиз ЗӘЙНИЕВ белән тиздән чыгачак «Камал комедияләре», татарның театр һәм уенга булган мәхәббәте, шәхси планнар һәм канәгатьлек хисе турында сөйләштек.

:: Ни өчен нәкъ менә Галиәсгар Камал һәм ни өчен нәкъ менә «Беренче театр» белән «Банкрот»?

– Театрда татарча комедия куясы килде. Аннан соң, күптән «петрушка», ягъни пирчәткә-курчакларның күренгәне юк иде. Гомумән, бары тик бу төр курчаклар белән генә уйнала торган спектакльләр бер театрда да калмады кебек. Гади генә тоелсалар да, пирчәткә-курчакларның мөмкинлекләре шактый. Шул ук вакытта алар өчен җитез уйнала торган материал кирәк. Без Камал комедияләренә тукталдык. Театрның 90 нчы юбилей сезонында театр турындагы спектакль чыгару – шулай ук матур күренеш бит. Шуңа да «Беренче театр» һәм «Банкрот». Беренчесе театр турында булса, икенчесе безнең халыкның театр җанлы, уйнарга яратуы турында.

Уен – безнең табигатебездә. Рус театрында да, татар театрында да эшләгәч, актерлар арасындагы аерма сизелә. Уен, уйнау татар артистларының канында бар. Аларга «кабынып», уйнап китү җиңелрәк. Ә рус актерлары озаграк «кереп китә».

:: Бу ике әсәрне бәйләп, инсценировка яздыгызмы?

– Инсценировка язмадык. Аларны менә шушы мин әйткән тема берләштерә. Пьесаларда үзгәрешләр бар, билгеле: үзебездән аз-маз текст өстибез, каядыр кыскартабыз, басымнарны үзгәртеп, үзебезгә кирәкле урыннарын ассызыклыйбыз.

:: Бу спектакль кем өчен?

– Гаилә белән килеп карый торган комедия ул. Карчыкның тамыр кайнатуыннан кала, балаларга күрсәтмәслек әйбер юк анда.

:: «Камал комедияләре»нең атамасында ук шәхескә мөрәҗәгать бар. Ә спектакльдә Галиәсгар Камал шәхесенә игътибар биреләчәкме?

– Без аның курчагын да ясадык. Спектакльгә матур гына кертеп җибәрәсе килә, ләкин ахыргача уйлап бетермәдек әле. Бәйли алсак, «Камал комедияләре»ндә Камал үзе дә булыр.

:: Юбилей сезонына «Әкият»леләр тагын ниләр әзерли? Бәлки, үзгәрешләр бардыр?

– Дөресен генә әйткәндә, үзгәрешләрне юбилейга бәйләп түгел, соңгы елларда гел кертеп торырга тырышабыз. Быел бишенче мәртәбә узачак «Әкият-LAB» курчак театрлары лабораториясенә бераз яңалыклар кертергә иде. Җәй көненә планлаштырылган «Шомбай-fest»ны юбилей белән берләштереп үткәрергә ниятлибез. Соңгы биш ел дәвамында мин Россиянең иң көчле режиссерларын, рәссамнарын «аулыйм», аларны театрга чакырам. Юбилей сезонында да кызыклы режиссерлардан кызыклы спектакльләр көтелә. Моңа өстәп гастрольләр, фестивальләр…

:: «Әкият»тә үз әсәрегезне куярга теләмисезме?

– Мин, гадәттә, инсценировкалар эшлим. Либретто буларак «Әлфия», «Шүрәле балеты» чыкты, «Тыпырдык»ны эшләгән идек. Һаман үз әйберемне кую бик дөрес булмас. Фикерләр бар барын. Безнең репертуарның 90 проценты – балалар өчен спектакльләр. Өлкәннәр өчен чыгарган бер спектакльгә 5–6 балалар спектакле тәкъдим итәбез. Һәм ул шулай тиеш тә.

> Дәүләт театры атаңнан калган мал түгел, кайда һәм ничек эшләгәнеңне чамаларга кирәк. Бу вазыйфага куйганнар икән, төп бурычың үтәлергә тиеш. Ә инде ул эшне киңәйтә аласың икән, бик яхшы. Тиеш әйберләр бар, аннан соң гына башкалары. Тиеш, мәҗбүр һәм башкача булырга мөмкин түгел.

«Канәгатьлек хисе кичермим…»

:: «Әкият»тән чыгып, Илгиз Зәйниев драматургиясе турында сөйләшик әле. Ни сәбәпледер, сез язган әсәрләр арасында комедияләргә игътибар күбрәк.

– Моның сәбәбен әйтү кыен. Миңа калса, яхшы комедия язу – бик катлаулы нәрсә. Шуңа алар сирәк. Мин комедия язсам, театрлар бик теләп сәхнәләштерәләр. Репертуарда минем әсәрләр күп булгач, драмаларымны да куйсалар, гел бер авторны кую була бит. Бәлки, шуңа драмалар читтә каладыр.

:: Шәхси планнарыгыз турында да ишетәсе килә.

– Мин, дөресен әйткәндә, бераз арып киттем. Аннан соң, театрның юбилее булгач, бу сезонда читтә куярга уйламаган идем. Чакыручылар бар барын. Планнар үзгәрмәсә, Псковта спектакль куярга тиеш. Әлмәтләр, Тинчуриннар чакырып тора.

:: Соңгы берничә айда ике зур эш башкарып чыктыгыз. «Кави-Сәрвәр» операсының премьерасы булды, ачык һавада янәдән «Кара пулат» күрсәтелде. Бу арулар шуларга бәйле түгелме?

– Төрлелек булу, киресенчә, кызык ул. Авыр, сүз дә юк. Мин бит 14 яшемнән пьеса язам. Елына ким дигәндә 7–8 спектакль чыгарам. Театр тарихында андый режиссер булса да, гасыр башында гына. Миңа менә шулай туры килде – театрлар белән элемтәләр әйбәт, үзем дә «юк» диярга уңайсызланам, яңа эшкә алынырга кызыгам.

:: Сез үзегездән, эшләрегездән канәгатьме?

– Моңарчы камил спектакль куйганым юк әле. Бар яктан да килгән… Хәер, алай була да алмыйдыр ул. Канәгатьлек хисе кичермим, кызганыч. Нәрсәгә бәйле икәнен дә белмим.

:: «Кави-Сәрвәр»дән дә канәгать калмадыгызмы?

– Сәхнә артында булгач, мин аны күрмәдем дә. «Кара пулат» – бер мәртәбә куелган спектакль, мин аны кабатлап кына куйдым. «Кави-Сәрвәр» – бөтенләй яңа материал. Билгеле, бу эшне башкарып чыга алуыма шатмын. Гәрчә мин аны эшләп чыга алмасам да, «опера куя белми икән» дигән мөһердән кала, дәрәҗәмә зур хилафлык килмәс иде. Мин Миләүшә (композитор Миләүшә Хәйруллина. – **Авт.**) өчен зур җаваплылык тойдым. Ул – аның беренче зур эше. Минем аркада аның язган операсы начар яңгыраса, опера була алмаса, бик зур югалту булыр иде. Бер татар композиторы сәләтсез Илгиз Зәйниев аркасында югалган булса, мин моны зур гөнаһ итеп кабул итәр идем. Асылда алай булмады дип уйлыйм. Аллага шөкер.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Блиц-сораштыру

– Соңгы караган спектакль?
– Татар театрлары булса, «Ситса туй» (реж. – Айдар Җаббаров. – **Авт.**).

– Соңгы укыган китап?
– Рус язучыларыннан – Федор Сологубны, татар әдипләреннән Фатих Әмирханны укыйм. Әле тагын улым белән кичләрен балалар өчен китап укыйбыз.

– Бу сорауны сезгә еш бирәләр. Ләкин режиссер һәм драматург буларак активлыгыгыз үзгәреп тора. Бүген сез, беренче чиратта, режиссермы, драматургмы?
– Соңгы берничә елда режиссура алга китте кебек. Драматургия өчен ялгызлык кирәк бит, тынычлык. Хәзер язарга утырам да, театр баштан чыкмый, бөтенләй читкә китәсең. Драматургиядә бары драматургия турында гына уйларга кирәк.

– Соңгы тапкыр кайчан яздыгыз?
– Көн дә аз-азлап язам. Берничә башлаган әйберем бар. Беренче чиратта Туфанга (Имаметдинов. – **Авт.**) пьеса язып бирергә тиеш. Бер ел көтә инде *(көлә)*, сабырлыгы өчен рәхмәт. Ittifaq җырлары белән лирик комедия булыр дип торабыз.

Хәзинә

Фикер

Дәүсовет утырышларының берсендә Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова чыгыш ясаган иде. Кайбер электрон мәгълүмат чараларында «депутатлар министрның сөйләгәннәрен тыңлап утырасы урынга, аның күлмәген карап утырдылар» дигәнрәк хәбәрләр чыккан иде. Әлбәттә, бу шаярту сымак кабул ителде. Ә асылда борынгы стильдә тегелгән милли күлмәк министр әйтәсе килгән фикерләргә ишарә иде. Чыгыш Татарстанда яшәүче халыкларның милли мәдәни мирасын саклау мәсьәләләренә багышланды.

tatarstan.ru

Хәтерләсәгез, 2022 ел – Россия халыкларының мәдәни мирасы елы дип игълан ителеп, рухи хәзинәне саклау турында махсус федераль закон да кабул ителде. Шунысын да әйтик: бу закон иң беренче чиратта Татарстанның теләк-ихтыярын исәпкә алып язылды. Тиңсез рухи байлыгыбызны саклау өчен хокукый нигез кирәк иде. Шөкер, анысы да булды. Шул ук вакытта сакланырга тиешле мирасны системага салып барлап тоту өчен дәүләт реестры да эшләнде. Министр Ирада Әюпова әйтүенчә, хәзерге көндә Татарстанның электрон реестрына 88 объект кертелгән һәм ел ахырына бу санның 98гә җитүе көтелә. Тик мирас объектлары күктән төшми. Алар җирдә, безнең арада, безнең күңелләребездә, аларга игътибар биреп кенә җиткермибез. Шуңа күрә Ирада ханым депутатларга үз районнарында матди булмаган этномәдәни мирасны саклау мәсьәләләренә игътибар итүләрен үтенде дә инде. Бу һәр мирас объектын җентекләп өйрәнү, аның тарихи, мәдәни, фәнни кыйммәтен билгеләүгә бәйле икәнен әйтсәк, хөрмәтле депутатларга җиң сызганып эшләргә туры киләчәк. Рәсми тел белән әйткәндә, «матди булмаган этномәдәни объектлар»ны федераль исемлеккә дә кертәсе бар әле, алар Россия дәүләте яклавында да булырга тиеш. Федераль реестрда бездән 4 кенә объект кертелгән, ди министр.

Быел тагын ике рухи хәзинә тәкъдим ителгән: «Татарларның календарь объекты – Сабантуй» һәм «Балтач районы керәшеннәренең гөслә ясау техника һәм технологиясе». Сабантуй турында сүзне озакка сузуның кирәге юк, ә менә гөслә – халыкның яратып уйнаган уен коралларының берсе. Хәтерлим: әле моннан утыз еллар элек Балтачның Субаш авылы гөсләчеләре белән очрашкан идем. Барысы да хатын-кызлар иде алар. Апалар яшьлекләрен, гөслә чиртеп кич утыруларын искә төшерделәр. Телевидениедән тапшыру эшләдек без алар турында, гөсләдә уйнап, җырлап утырдылар, гөсләләрне үзләре ясаулары, үзләре көйләп тотулары турында сөйләгәннәре дә истә калган. Ни өчен бу турыда язам? Без халык иҗаты, милли уен кораллары, халык һөнәрчелеге, йола-бәйрәмнәребез турында «анда бер, елга бер» генә искә төшерәбез. Нинди байлыкка ия булуыбыз турында даими язып, радио-телевидение аша тыңлатып-күрсәтеп торырга иде.

Мәдәният министры әйтүенчә, быел июнь аенда Россия Думасының Мәдәният буенча комитеты күчмә утырыш уздырган. Депутатлар Россия халыкларының мәдәни хәзинәсен, шулай ук телне, халык һөнәрчелеген саклау, баету өчен хокукый нигез булдыру турында сөйләшкәннәр. Димәк, мәдәният-сәнгать, һөнәрчелек, тел өлкәсендә милли төрлелек дәүләт яклавында булырга тиеш. Ирексездән, заманында татар дөньясында яхшы ук танылган Арча милли аяк киемнәре фабрикасы язмышы искә төште. Авылларда филиаллары да бар иде аның. Хәтерлим: туган авылым Субаш Атының тегү эшенә куллары ябышып торган хатыннары чүәкләр тегәләр, чигәләр иде. Командировкага районнарга чыккач, Арчадан икәнемне әйтүгә, миңа читек алырга заказ биргәннәре дә хәтердә. Һәм, үзен акламый дип, фабриканың ябылуы да истә әле. Күрәсең, милли һөнәрчелек дәүләт яклавында булмаган. Ә бүген министрыбыз Ирада Әюпова Арча данын янәдән күтәрмәкче. Халык һөнәрчелеген саклау һәм үстерү максаты белән туристик кластер булдыру турында сөйләшүләр бара икән. Бу уңайдан фабриканың яңадан эшли башлавы да кирәк, диде министр һәм ярдәм-яклау сорап депутатларга да мөрәҗәгать итте.

Язманы Ирада ханым өстендәге милли күлмәкне телгә алып башлаган идек. Минем өчен милли кием – теге яки бу милләт халкы күңелендәге милли рухның чагылышы. Бу рухка бәйле һәрнәрсә – мәдәният, йола-бәйрәмнәр, һөнәрчелек, халык иҗаты, тел дә – халыкның олы хәзинәсе. Бу байлык юкка чыга, әрәм-шәрәм ителә башласа, милләт тә бетә. Аның яшәешендә милләтне милләт иткән бер генә билге дә калмый дип уйлыйм.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Якташлар очрашуы

ӘТНӘЛЕЛӘР ӘЙТТЕРӘ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Әтнә халкы сәхнәсез яши алмый. Бу элек-электән шулай булган, хәзер дә. Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан берничә көн элек Камал театрына зур тамаша әзерләп килгәннәр иде алар. Анда да шул фикерне җиткерделәр. Әмма Әтнәдә эш кайгысы беткән икән дип уйлый күрмәгез тагын. Өлгер, уңган, җитез булулары театр фойесында оештырылган күргәзмәләрдән дә бик яхшы күренде.

Театр мәгърифәткә юл ача

Театрлы төбәк булгач, уен-көлкесез булмый, әлбәттә. «Әтнә көе»н әйттерүләре булды, артистлар, репетициягә йөреп, эш калдырулары турында гәпләшә башладылар. Тик шулай да араларында, ташлыйм, йөрмим, дигән кеше табылмады. Клубны бикләп китүләре булды, сәхнәдә рухлар пәйда булды. Менә алар тарихны белә дә белә инде. Бүгенге тормыштан да хәбәрдар. Ялкау дигәне: «Шаккатам мин кайчак. Ничек инде «Әтнә көе»н җырлаганда сыер турында уйлап торырга була ул, ә?» – дип артистларны тәнкыйтьләп тә алды. Төгәл исемлесе исә болай дип җавап бирде: «Әтнә авыл хуҗалыгы районы бит, оныттыңмыни? Шуның кадәр мегафермаларың була торып, сыер турында уйламагач, ни була инде ул? Бары тик Әтнәдә генә бер сыердан көнлек савым 31,5 литр тәшкил итә бит!» Зыялы гына аптырап утыра: «Да-а-а, егетләр, театрга 105 ел тулды дигәндә, тагын шул крәстиян темасына килеп төртел инде. Шуннан башланды, шуңа килеп төртелде».

Сүз дә юк, сәхнә рухлары театр тарихы турында онытмаган. Менә Шук китап тартып чыгарды: «Соң оныттыңмыни? Мөхәммәт Парсин кайткан елны. 1918 елның актыкларында Әтнә авылында татарча театр куярга ниятләдек. Авылдагы иң зур мәктәпне сайлап алып, бер читендә сәхнә ясадык. Фәхриевнең «Бәхет кошы» дигән нәрсәсенә әзерләндек. Моңа кадәр театр дигән нәрсәне күрмәгән Әтнә халкы җыелды…»

Әтнәнең мәгърифәтле як икәненә дә басым ясады сәхнә рухлары.

1918 ел, 16 гыйнвар. Бәрәскә авылы мәчетендә Габделкәрим улы Сөбхан белән аның улы Баһаветдин. Шиһабетдин исемле оныкның туу сөенечен уртаклашалар. «Бабасы Казан алынганнан соң төзелгән беренче таш мәчеттә имам-хатыйп булсын да, ничек оныгыннан галим чыкмасын инде», – диешәләр. Фаразлары тормышка аша: Шиһабетдин Мәрҗани зур галим булып җитешә. Петербург университеты мөгаллиме, тарихчы, этнограф Хөсәен Фәезхановның да Бәрәскәдә укыганын онытмыйлар. Революциягә кадәр бөтен Рәсәй белән сәүдә иткән Бәрәскә, Мәңгәр байларын да искә төшерәләр. «Тарихчыларга ышансак, Мәңгәрдә генә ике дистәгә якын ике катлы бай йортлары булган», – ди Көзге. Ә бөек Тукай! Кушлавыч Мәңгәр волостена кергән ул вакытта. Тукай Әтнә базарына Мәңгәр аша килеп йөргән.

Шулай да Ялкау: «Халыкны җыеп торучы районсыз, эш биреп торучы колхозсыз халык үзе генә ни эшли ала?» – дип әйтергә булды. Ни дисәң дә, биеп-җырлап кына дөнья бармый бит әле. Ашарга, киенергә, яшәргә кирәк дигәндәй. Хәер, Әтнә халкы нинди өлкәдә дә сынатмый үзе. Әмма үз районы булмаганда да мәдәнияте үз урынында кала. Ул елларда театр җитәкчесе Гомәр Мәрдановны күпме Арчага чакырып карыйлар, әллә ниләр вәгъдә итәләр. «Минем Әтнәдә – коллективым. Авылга да ияләндем. Күчмим», – дип кенә җавап бирә.

Якташлар

Сәхнә рухлары бүгенге тормышка да мөкиббән. Рәхәтләнеп телевизор карыйлар. Пультны баскалап, якташларын эзлиләр. Кинәт кенә экранда Яңа Шимбер авылы егете, Татарстан Рәисе Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров пәйда була. Әнә Марсель Сәлимҗанов күренеп ала. Фәрит Бикчәнтәев тә шунда. Алар янында Наилә Гәрәева белән Люция Хәмитова. Кинәт кенә Мыраубатыр килеп чыга. Башта аптырап калалар. Аннары исләренә төшә. Анысы да якташ икән бит. Мыраубатыр – Бәрәзәдән. Аны уйнаган Илдар Хәйруллин – Бәрәскәдән. Камал театры коллективының яртысы Әтнәдән дип уйларсың, билләһи. Шуңа күрә әлеге театр белән туганнарча яши дә инде әтнәлеләр. Ул арада Көзге белән Шук пульт өчен тарткалашып, төшереп ваттылар. Экрансыз калгач, тамашачылар янына артистларның үзләрен алып килергә туры килде. Монысы да урынлы булды әле. Һәрберсе Лена Шагыйрьҗан, Сибгат ага Хәким, Гөлүсә Батталова кебек Әтнә җирлегеннән чыккан шагыйрьләрнең шигырьләрен бүләк иттеләр.

Бүген

Тамаша оештырып, арып та китте бугай сәхнә рухлары. Әмма гасырлар буена шулай яшәлгән бит инде, туктый белмиләр. Бәхәсләшәләр дә әле. Ялкау, ялкаулыгына карамастан, сөйләп алырга да иренми: «Дөресен генә әйткәндә, бу бәхәснең чишелеше үткәндә түгел. Хәзерге көндә һәм киләчәктә. Карагыз сез сәнгать мәктәбен, карагыз театрны, мәктәпләрне, йолдызлык сәхнәсен, башка фестивальләрне… Анда бит яңа буын. Бүген Әтнәнең данын күтәрерлек алмашыбыз, хезмәттә дә, сәнгатьтә дә сынатмаслык балаларыбыз бар. Үзешчән ансамбльләр, халык ансамбльләре, халык театрларыннан Дәүләт театры үсеп чыккан икән, димәк, без дөрес юлда!»

Ялкау сүзен дәлилләрлек күренешләр күп булды сәхнәдә. Укучыларның «Алчәчәк» үрнәк хореография коллективы «Чәпәләй» биюе белән тамашачыларны сөендерде. «Әтнә гимны»н башкарган Риваль Хисмәтуллинны аягөсте басып алкышладылар. Сөмбел фольклор ансамбле чыпта сугып күрсәтте. Ә гармунчылар… Әтнәдә гармун уйнамаган кеше юк, ахры, дигән фикер калды тамашачыларда.

Әтнә районы башлыгы Габделәхәт Хәкимов та шундый фикердә:

– Халыкта «Икмәк булса, җыр да була» дигән гыйбарә бар. Бу Әтнә халкына бик тә туры килеп тора, – диде ул. Башкала тамашачысын сөендерү кебек гореф-гадәтләребез тагын шулай дәвам итсен иде, дигән теләктә калды.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Танырлыгы калмаган

Бер акыл иясе: «Егетне авылдан тартып чыгарып була, ә менә авылны егеттән тартып алып булмый», – дигән. Шуңа да авыл тормышы, авыл кешеләре бигрәк тә якыннар күңелдә гомер буе безнең белән яши бирәләр. Авыл бит ул үзенә күрә бәләкәй дәүләт кебек. Анда төрле кызыклы хәлләр булып тора.

Минем әткәй бик мәзәкчән кеше иде. Үзебезнең авылда гына түгел, тирә-юнь авыл кешеләренең дә ихтирамын яулады. Алда сурәтләнәчәк кызыклы хәл аңлаешлырак булсын өчен, әткәйнең физик яктан бик көчле, каты куллы кеше икәнлеген дә әйтеп үтмичә булмый. Аның шаяртып кына төрткәне дә чынлап торып суккан кешенекеннән катырак була торган иде. Үзем күргән хәлне түгел, әткәйнең сөйләгәнен искә төшереп язам.

Безнең авылда Закир абый яшәде. Ул бик гади, бик тә оста куллы кеше иде мәрхүм. Һәр кешенең үз гадәте була. Закир абыйның да үзенә генә хас гадәте бар икән. Ул чиле-пешле йомырка ярата торган булган. Алай гына да түгел, ул бер-икесен үзе белән эшкә дә ала икән. Шулай көннәрдән бер көнне әткәйгә очраган бу. Әткәй моның йомырка ашарга җыенганын күреп алган да: «Закир, чиертеп ватыйммы шушы йомырканы?» – дигән. Әгәр тырышып караганыгыз булса, йомырканы чиертеп вату мөмкин түгел диярлек. Әлбәттә, Закир абый да моны белгәнлектән: «Әйдә, ват!» – дигән.

Әткәйгә шул гына кирәк: «Югарырак тот!» – дип, өскәрәк, бите турысынарак күтәрткән моның кулын. «Закирның кулындагы йомыркага чиертеп тә җибәрдем, ул ватылып кына калмыйча, чәлпәрәмә килеп, Закирның битен сарыга манды. Танырлыгы калмады», – дип көлә-көлә сөйләгән иде әткәй.

Әткәйнең нинди кеше икәнлеген белгәнлектән, Закир абый үпкәләмәгән: «Нәрсә эшләдең инде, ач калдырдың бит!» – дип сукрана-сукрана юлын дәвам иткән.

Хәзер инде кемне искә алма – шул юк, урыннары оҗмахта булсын! Язган сүзләрем дога булсын!

Илсур МОРТАЗА,
Татарстанның атказанган артисты

vk.com

Илдар Мөхәммәтҗанов

Көзнең беренче ае да төгәлләнеп килә. Һава торышы исә җәйне хәтерләтә. Күңелләрдә сакланырга тиешле сирәк була торган халәт бу. 2023 елны гел-гел искә төшерербез әле.

«ЙӨЗ ЯШЬЛЕК» ИНӘКӘЙ

Без, алты малай, әниебезгә «инәйинәкәй» дип эндәшеп үстек. Тормышы бик авыр була аның. Чәчәктәй чагында, дәһшәтле сугыш чыгып, җитеп килгән кызларны абый-агалары урынына тракторга утыртырга кыска курсларга укырга җибәрәләр. Алар җир сөреп, чәчеп, ипекәй үстерә дә, тизрәк җиңү өчен дип, фронтка озата. Шул чәчәктәй кызлар, каты имән кебек, кайда кыен – шунда, атна буе көне-төне тракторда эшләп кырдан кайткач, Ык буе җәйләвенә сыер саварга да китәләр. Һәр көнне сафта – зар-интизар итүләр уйда да юк. Яшь чак – яшь чак инде ул, эшең авыр булса да, кояш чыгу белән башланып, төн караңгысына кадәр эшләнсә дә, барыбер кичке клуб утлары, тальян гармун моңы үзенә тарткан. Әгәр шулай булмаса, әле яңа гына сугыш дәһшәтеннән яраланып кайткан яшь егет – әткәебез белән кавышып та китмәсләр иде. Мәхәббәт – мәхәббәт инде, инәкәебез ярты гәүдәсе генә калган димәгән аны, моң иясе – гармунчыга кияүгә чыккан да куйган. Аннары киткән: малайлар ике ел саен дөньяга килгән, алтыга җиткән. Әткәй – гармунчы-музыкант, авылның клуб мөдире – мәдәният халәтен үз өстенә алган. Инәкәй җәй буе урманда аркылы пычкы белән тау-тау утын әрдәнәләре әзерләп, кыш буе агач биналы класслардагы йөзләгән мичләрне, таңнан торып, ягып-җылытып, балаларны көткән.

Мин инәкәйнең ял итеп утырганын хәтерләмим. Әгәр утыра икән – оек яисә бияләй бәйли, йә булмаса иске кием ямый. Ул да булмый, ялтырап шомарган урагын алып бакча артындагы яшь кычыткан хәтфәләрен кырып-чабып алып кайта да турап-тапап бирү мәшгулендә була. Җәһәт кенә пешеренергә, җылынырга зәңгәр ягулык та юк, мичкә ягарга утыны да бик кадерле – кояшта киптергән тирес «утын»ы да җитәр. Инәкәй мәктәп миченә ягып

кайткач, үзебезнең шул тирес «утын»ы мичендә без – алты малайга, өстәвенә әбекәй һәм инвалид әткәйгә таба-таба бәрәңге тәкәләре, үзебез тоткан балыктан пироглар, көлчәсен салып, пешереп өлгертә, өлгермәсәң, башкача пешерер урын юк. Аннары ул бу «гвардия»не ашатып, карап-киендереп мәктәпкә җибәргәч, мич төбенә, итен, бәрәңгесен салып, чуен чүлмәкне тыгып куя.

Инәкәй Саимә Гобәйдулла кызы Сәгытдинова безне шулай үстерде, әле ничек кенә! Әткәй 44 яшь тулганда сугыш яраларыннан кинәт кенә китеп барды. Без барыбыз да әнкәй карамагында. Бәләкәйдән кул арасына кереп, бөтен эшне белеп үсәргә өйрәтте, укытты-тәрбияләде. Беребез – филолог-журналист, икенчебез – мал табибы, хуҗалык җитәкчесе, өченчебез – терлекче, игенче-фермер, башкаларыбыз – техника, төзелеш осталары. Бу араларда аңа 100 яшь тулган булыр иде. Безнең бөтенлек-исәнлек өчен, туган-тумача, авылдашларның саулыгы, бәхете-шатлыгы өчен үзен аямыйча яши торган кеше иде инәкәебез. Урыны оҗмахта булсын!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы

Кайтсана язларда...

Кайтсана язларда, кайтсана көзләрдә,
Кайтсана төшләрдә, кайтсана өннәрдә.
Кемнәргә кадерләп эндәшим көннәрдә,
Кемнәрнең сагышын ишетим төннәрдә?!

Кемнәрнең сокланып багармын күзенә,
Кемнәрнең ышанып яшәрмен сүзенә...
Кемнәрнең иңенә башымны салырмын,
Кемнәрнең назларын җаныма
алырмын...

Кайтсана өннәрдә, газаплы көннәрдә –
Кемнәрнең җылысын тоярмын,
кемнәрдә...
Кайтсана җәйләрдә, кайтсана кышларда,
Кайтсана охшатып канатлы кошларга.

Канатлар кагынып дөньяны сагынып,
Кайтсана таңнарның нурларын
ябынып...
Кайтсана, ялварам, алдыңа тезләнәм,
Җиремдә, күгемдә, һәммәдә эзләнәм.

Юлларда адашып, язмышта саташып,
Яшимен галәмдә үзлегем алдашып...
Кайтсана кабаттан, мизгелгә булса да,
Югалту-сагыштан кайнар яшь тулса да:

Үткәннәр хакында яңартып хисләрне,
Тын гына каршылыйк айлы
тын кичләрне...
Искәрик, яңартыйк җиһанның төсләрен,
Күңелдән кичерик садәлек көчләрен...

Иңнәрдә, кочакта назларың сулышын
Мәңгегә сакларга күңелең тулышын...
Кайтсана, ишетми югалган серләрне
Кабаттан яңартыйк үткәннең көннәрен...

Миләүшә ӘХМӘДУЛЛИНА.
Кукмара районы
Күкшел авылы

УЛ ҺАМАН БЕЗНЕҢ БЕЛӘН...

Алабуга мәдәни-агарту училищесының китапханәчеләр бүлеген моннан 51 ел элек тәмамлаган кызлар, яңадан табышып, очрашырга җыенабыз. Хәтер сандыгында күп нәрсәләр җуелса да, кайбер йөзләр томан эчендәге сурәт кебек тоелса да, якты булып, балкып торучы шәхесебез – укытучыбыз, группа җитәкчебез Дибәҗә апа Каюм кызының исеме дә, үзе дә онытылмаган. Укытучылар елында искә алмау гөнаһ булыр төсле.

1970 елның 1 сентябре. Без, 30 кыз, группа җитәкчесен көтәбез. Менә бүлмәгә 35 яшьләрдәге, кызлар кебек нәфис гәүдәле, мөлаем йөзле укытучы килеп керде. Үзе белән гади генә итеп таныштырганнан соң, кемнең кайсы яктан икәнен сорашты. «Кем Актаныш якларыннан?» – дигән сорауны ишетүгә, күңелемә җылы йөгерде. Ялгышмаганмын: укытучым Татар Ямалысы авылында туып-үскән икән.

Шул көннән башлап, Дибәҗә апа үзе белән әдәбият дигән серле дөньяга ияртеп китте.

«Сөйләм культурасы» дәресендә безне матур, дөрес итеп сөйләшергә, сүзнең тәмен, көчен тоярга өйрәтү укытучыбызга җиңел бирелмәгәндер, чөнки күбебез Минзәлә сөйләмен куллана. Чистай, Спас яклары кызларының үз сөйләмнәре. Әмма Дибәҗә Каюмовна беркайчан да тавышын күтәрмәде, алдыбызга көзгеләр куеп, авазларны дөрес әйтергә өйрәтте.

Укытучыбыз җилкәсендә нинди зур йөк йөрткәнен без соңрак аңлаганбыздыр, мөгаен. Утыз кыздан торган төркемне исән-имин зур тормыш юлына озату өчен күпме көч куйгандыр ул.

Эдуард Касыймовның «Бир кулыңны, дустым» әсәрен һәрберебезгә укытты. Соңыннан, фикер алышканда: «Кызлар, ышанмагыз, тормышта Әхсән кебекләр җитәрлек. Робертлар юк дәрәҗәсендә», – дигән сүзләре бүген генә әйтелгән кебек тоела.

Группаның махсус көндәлеген Мәдинәбез алып барды. Альбомның беренче битендә девиз язылган: «Дуслык. Белем. Тәртип». Ике ел уку дәвамында без бу сүзләргә тугры булырга тырыштык. Тормышта үз юлыбызны булдырганбыз икән, аның башында, һичшиксез, кадерле укытучыбыз Дибәҗә Каюм кызы тора.

1934 елның 22 ноябрендә Татар Ямалысы авылында уникенче бала булып дөньяга килгән кызчыкка Дибәҗә дип исем кушалар, гарәпчәдән тәрҗемәсе – «китапның титул бите». Әтисенең күңеле сизгәндер кызының укытучы буласын, китаплар язасын, көйләр иҗат итәсен.

55 яше тулып, лаеклы ялга чыккач, укытучыбыз иҗат эшенә чума. Бөек Җиңүнең 55 еллыгына «Халык күңелендә мәңгегә» дигән исемдә Алабуга районының Хәтер китабы дөнья күрә. «Кыз бала», «Өзелгән шомырт чәчәкләре», «Буранлы юллар», «Йөрәк серләрем» һәм «Бергә чакларда» җырлар җыентыгы укытучымның култамгасы белән кадерле ядкарь булып саклана.

Юбилеен үткәргәндә, якташыбыз Леонид Арсланов: «Дибәҗә, безне Алабугада беләләр, Актаныштa белмиләр. Кайтыйк әле Актанышка», – дигән иде, ачынып.

Кайтты Дибәҗә Каюмова Ямалысына. Безнең Актаныштa 2016 елдан «Кече Ватан» проекты гамәлдә. Китапханәләр, мәдәният йортлары үз җирлекләрендә туып-үскән күренекле шәхесләрне барлыйлар. 26 июль көнне Татар Ямалысы авылында Дибәҗә апа Каюмованы искә алу кичәсе үткәрелде. Кызлары Алсу һәм уллары Алмаз катнашында уздырылган бәйрәмдә мин укытучым өчен горурланып утырдым.

Уку йортының хәзерге директоры, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Әлфирә Әкбәрова: «Киләсе елда, 90 еллыгына багышлап, Дибәҗә Каюмова турында китап чыгарырга ниятлибез. Бик җаваплы эш, булышучылар табылыр дип ышанабыз», – диде. Бирсен Ходай. Без, Дибәҗә апаның укучылары, истәлекләребез белән уртаклашырбыз, исән-сау булсак, Алла боерса.

Гөлдәлифә ӘХМӘТГАЛИЕВА.
Актаныш районы Качкын авылы

Яшьлек хатирәләре

ИСКЕРЕП БАРАМ ИНДЕ...

Оныклар – көтеп алынган, зур өметләр баглаган дәвамчыларыбыз. Онгыгыма 3 яшь. Шаян инде. Баштан йөри, кем әйтмешли. Кырынрак сүз әйттем, ахрысы, уенын ташлап, каршыма килеп басты да, миңа карап, сүз эзли бу. «Картайгансың инде, бабай, берни аңламыйсың», – дип әйтә дип көтсәм, «Искергәнсең инде син, бабай», – дигән сүзне сылады да уенын дәвам итте.

Бер оныгым 3 нче сыйныфта. Бик яхшы сәпид алдым, җиде тоташтыргычлы, бик яхшы йөрергә тиеш. «Менә чирәм чыксын да, Сабаның велосипед юлына ярышка чыгам һәм беренче булып киләм», – дип әйткән идем, «И-и, бабай, бу яшеңдәме? Сөйләп тә күрсәтәсең инде син», – дип, ышанмавын белдерде. Мин дә үз сүземне бирмим. Оныгым: «Бабай, булдыра алмыйсың. Әйдә, 600 сумнан бәхәсләшәбез», – дип тәкъдим ясады. «Әлбәттә, мин беренче киләм, чөнки юлда берүзем генә булам бит», – дигәч, оныгымның ничек гаҗәпләнгәнен күрсәгез иде! Көлеп үлгән булыр идегез.

Оныгымның баласы – туруным үсеп килә. 4 яшьлек вакыты. Әнисе ярмалы аш пешергәч, ботканы ашка салгансың дип битәрли икән. Аның әнисе – минем оныгым. Берсендә әнисенең барасы җире булып, тиз генә пилмән өлгертеп алыйм дисә: «Әппәйт пилмән! Башка төрле ризык пешерә белмисеңме әллә син?» – дип әрләп аткан.

Бер оныгым авырып киткән. Температурасы да бар. Хәлен белим әле дип телефонына шалтыраткан идем: «Что вам надо?» – ди. Иптәш малайлары шалтырата дип белде, ахрысы. «Улым, кәефләрең ничек?» – дигән идем, «Бабай! И-и, бабай, синмени?» – ди, гафу үтенгән сыман итеп. Шул көнне үк минем исемне язып куйды телефонына. Афәрин!

И балалар, сәламәт, гомерле, бәхетле булсагыз иде. Шулай, мин исә искереп барам инде, бөтен өмет сездә.

Мәгъдәнур ГАТАУЛЛИН.
Байлар Сабасы

ЗӘҢГӘР ЯУЛЫК – КОДАГЫЕМ БҮЛӘГЕ

Минем истәлекле, кадерле яулыгым бар. Әйтерсең лә зәңгәр күккә ай, йолдызлар чигелгән. Карап кына торасы килә.

Без, 11 бала, Балтач районы Арбор авылының су буйларында тәгәрәшеп үстек тә Җир шарының төрле почмакларына таралыштык. Хәзер җыелышып бер сөйләшеп утырасы килеп уза гомерләр.

Унынчы бала Фәридә Лаешта икътисадчы булырга укыды һәм Мамадыш районы Көек-Ерыкса авылына эшкә билгеләнде. Ап-ак чәчле, зәңгәр күзле матур кызны ошаталар биредә. Рәүф атлы егет белән араларында мәхәббәт уты кабынып өйләнештеләр һәм өч бала үстерделәр. Аларга гел барып, аралашып яшәдек. Кодагый бик ипле кеше иде, сөйләшеп сүзләр бетмәде. Зәңгәр яулык – аның истәлеге. Үзе мәрхүмә инде, сүзләрем дога булып барып ирешсен. «Яулыкны алган саен мине исеңә төшерерсең. Әле ярый очрашып тордык, диярсең», – дигән иде.

Кияү – теш табибы, аларга ешрак барылды инде, якын да. Туганнар Әрмәнстан, Кыргызстан, Украина, Чиләбе, Чаллы, Мамадышта. Әти-әни исән вакытта кайтып йөрделәр. Алар киткәнгә дә 23 ел булды.

Сания ШӘФИГУЛЛИНА.
Балтач районы

АЯК КИЕМЕ НИ ӨЧЕН?

Бездә – Баулы районының Исергәп авылында хатын-кызның атын ире исеменә ялгап сөйләү гадәте бар. Җәмилә апаны да Мөлек Җәмиләсе дип йөрттеләр. Мин белгәндә Җәмилә апа ялгыз яши иде. Улы Баулыда, кызы кайдадыр еракта кияүдә, диделәр. Хәзер генә ул, машина бар, хәл белергә кайтып була, элек исә кайтып-китеп йөрүләр сирәк иде шул. Картайган көнендә дөнья йөген ялгыз тартты апабыз. Тормышы да әллә ни бай түгел иде: кәҗә тота, бәрәңге утырта – бары шул. Печәнне, утынны бәләкәй арба белән ташый. Бер елны бөтен авылның бәрәңгесе чиреде, без орлыкка бәрәңгене Җәмилә ападан алдык. Инәки аның бәрәңгесе череmәүнең серен дә сөйләде. Казып алгач, һәр бәрәңгене чүпрәк белән сөртеп, алъяпкычына җыеп, өенә кертеп киптергән икән. Башка сере дә булды микән – анысын белмим.

Җәмилә апа кеше арасына бик чыгып йөрми, авыл яңалыкларын белергә сирәк булса да безгә кергәли иде. Кибеткә товар кайта башлаган заман бу. Барыбыз да резин аяк киеме алып кидек. Җәмилә апа да алган, әмма һаман яланаяк йә чабата киеп йөри. Инәкинең: «Нишләп кимисең сапогиеңны?» – дигәненә «Бу пычракта ничек киясең шундый матурны, сандык өстендә генә тотам мин аны», – дип җавап бирде.

Зәрия ХӘБИПОВА

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Өлкәннәргә дә, яшьләргә дә мөрәҗәгать итүебез: нәкъ менә балачактагы хатирәләрне күңелегездә яңартып, «Һич онытасым юк» сәхифәсенә язмалар юллагыз әле. Үзегезгә үткәнгә кайтып килү булса, башкаларга соклану, йә булмаса гыйбрәт алу булыр.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Эшләр идарәсе күчермәләр ясау-күбәйтү бүлеге җитәкчесе

ВӘЛИЕВ Фәрхат Абдулбарый улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест

ӘКИЯТ ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

Җир йөзендә әкият яратмаган кеше юктыр. Чөнки ул – үзенә күрә бер үзенчәлекле, сихри дөнья. Аларны балалар да, өлкәннәр дә ярата. Әкиятләрне искә төшереп, могҗизалар булган тылсымлы дөньяга сәяхәт итеп алыйк.

1 **Тылсымлы әкиятләрдә вакыйгалар ничә тапкыр кабатлана?**
а) 1;
ә) 3;
б) 7.

2 **«Өч кыз» әкиятен кем язган?**
а) Габдулла Тукай;
ә) Нәкый Исәнбәт;
б) халык.

3 **Бара болар тукталмастан,**
һаман бара,
Күрә болар: ерак түгел бер ут яна.
Бу юллар кайсы әкияттән?
а) «Бүдәнә белән Төлке»;
ә) «Су анасы әкияте»;
б) «Кәҗә белән Сарык».

4 **Гуцул халык әкияте.**
а) «Хәйләкәр керпе»;
ә) «Әтәч патша»;
б) «Бүдәнә белән Төлке».

5 **Татар әкиятләрендә очрый торган тылсымлы предметны тап.**
а) тәрәзә;
ә) тарак;
б) ачкыч.

6 **Автор әкиятен билгелә.**
а) «Борынгы әкият»;
ә) «Гөлчәчәк»;
б) «Бүдәнә белән Төлке».

Җаваплар: 1. ә); 2. б); 3. б); 4. а); 5. ә); 6. б).

Киңәш-табыш

Баш мие яхшы эшләсен, дисәгез...

Баш мие бөтен тән энергиясенең 2 процентын куллана икәнен белә идегезме сез? Димәк, аның ничек «эшләве» турыдан-туры без тукланган ризыкка бәйле булып чыга. Баш мие өчен түбәндәге файдалы ризыкларны рационыгызга кертергә киңәш итәбез.



Авокадо
Әлеге продуктта баш миенең төзелешен саклый һәм кан әйләнешен яхшырта торган файдалы майлар бар.

Брокколи
Баш мие эшчәнлеген яхшырта торган К витамины чыганагы. Олыгаю белән килә торган хәтерсезлектән дә саклый.

Шпинат
Нерв күзәнәкләренең сәламәтлеген саклый, баш мие эшчәнлеген активлаштырырга ярдәм итә.

Кабак төше
Анда организм һәм баш мие өчен бик кыйммәтле матдә – цинк бар, ул хәтерне яхшыртырга ярдәм итә.

Сәхифәне Ләйсән САФИНА әзерләде

БУЛАТ НУРГАЛИЕВ:

«КӨНДӘШЛӘРЕМ МИННӘН КУРКЫП ТОРДЫ»

Булат Нургалиев – Россиядә дрон операторлары арасында иң яше. Август башында ул «Архипелаг – 2023» дрон ярышларында җиңүче булды. Пилотсыз очу аппаратларының яшь операторы тугыз кубок һәм медаль яулады. Уңыш сере нидә? Киләчәккә нинди планнары бар? Булат белән әнә шулар турында сөйләштек.

:: Булат, пилотсыз очкычлар белән кызыксынуың ничек башланды?

– Мин һәрвакыт пилот булырга хыялландым. Дроннарны сынау белән өч ел элек кенә кызыксына башладым. Башта визуаль очышлар белән таныштым, бер елдан соң FPV форматына (видеоны реаль вакыт режимында мониторга, күзлеккә яки пилот шлемына трансляцияләү) күчтем. Мине әлеге кызыклы һөнәргә җәлеп итүе өчен әтием Марсельгә бик рәхмәтле. Хәзер ул – пилотсыз авиация буенча Татарстанның җыелма командасы тренеры.

:: Син – иң яшь оператор. Күпкә өлкәнрәк һәм тәҗрибәлерәк булган көндәшләрең үзеңне ничек кабул итте?

– Барысыннан да яшьрәк булгач, башта миңа балага караган кебек карадылар. Аннары үземә җитдирәк мөнәсәбәтне сиздем, хәтта куркалар кебек иде. Мин үземне танылган шәхес дип әйтә алмыйм, ләкин алар минем турында ишетеп беләләр иде.

Өйдә бүләкләр өчен махсус киштәм бар, мин инде аларның күпме икәнен дә белмим.

:: Син идарә иткән дрон трассада көндәшләреннән тизрәк очып, өч самолетны бәреп төшерде. Уңышыңның сере нәрсәдә дип уйлыйсың?

– Ярышлар җиңел булмады. 12 бүләк алу өчен күп көч куярга, бик нык тырышырга туры килде. Анда бит бөтен Россиядән җитди көндәшләр җыелган иде. Әмма мин үземнең җиңүемә ышандым. Мин һәрвакыт үз-үземә ышанам. Көндәлек күнегүләр дә үз нәтиҗәсен бирде дип уйлыйм. Көненә 6–8 сәгать әзерләндем. Минем җиһазларым да бик көттә иде. Реакциям көндәшләрнекенә караганда тизрәк булды. Белмим, бәлки мин – бала, ә алар олылар булганга шулай килеп чыккандыр ул.

:: Күптән түгел син Россия Президенты Владимир Путин белән дә очраштың.

– Президенттан Россиядә дроннар белән кызыксынучылар өчен коптер-парклар булдырырга сорадым. Аңа минем идеям ошады, моны эшләүнең мөмкин булуын әйтте. Мин моңа бик шатландым, чөнки дроннар белән мавыгучыларның легаль рәвештә оча алуын телим.

:: Булат, киләчәккә нинди планнарың бар?

– Мине Мәскәүдәге зур компаниягә дроннар җыярга чакырдылар. Ләкин мин бармадым. Миңа укырга кирәк һәм мин киләчәгемне Казанда гына күрәм. Үскәч пилотсыз очу аппаратының профессиональ операторы булып эшләргә телим. Хыялым – граждан авиациясе пилоты булу һәм үз илемә ярдәм итү. Граждан самолетларын йөртергә дә өйрәнәсем килә. Мәктәптән соң очучылар әзерләүче училищега укырга керергә ниятлим.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Кунагыбыз турында белешмә

- Булатка – 14 яшь.
- Казанның 6 нчы гимназиясендә 8 нче сыйныфта укый.
- Үз куллары белән 20дән артык очу аппараты җыйган.
- Граждан авиациясе пилоты булырга хыяллана.

Хикәя

РӘХМӘТ СИҢА, ПЕСИ!

Дөньяда фәннең көче җитмәстәй могҗизалар гел булып тора. Андый чакта атаклы галимнәр дә үз гомерләрендә бер тапкыр иңбашларын сикертеп, «Йә, Хода!» – дия торгандыр. Шундый вакыйгаларның берсе галәмдә, Киек Каз Юлында булды. Көтмәгәндә ике йолдыз үзара сөйләшә башлады.

– Җир планетасында яшәүче Кеше дигән зат бигрәк юләр инде, – диде йолдызларның берсе.

– Ник алай дисең, дустым?

– Алар җыен ырымнарга ышана.

– Ягъни?

– Әнә Җиһангир исемле егетне күрәсеңме? Ул Гөлкәй исемле кызга гашыйк. Әмма Гөлкәйнең аңа тамчы да исе китми, ул 11 нче сыйныф укучысы Альбертны ярата. Ә Җиһангир бу минутларда, берәр йолдыз атылмасмы дип, төнге күккә карап тора. Атылса, «Гөлкәй миңа гашыйк булсын иде», – дип теләячәк.

– Һе... – диде икенче йолдыз. – Әйдә, кызык итәбез үзен! Мин хәзер атылам. Тик ырымнарга ышанып йөрсен шунда. Гөлкәй барыбер аңа карамаячак.

...Төнге күкне ярып атылган йолдызны күргәч, Җиһангирның тәннәре чымырдап китте, егет шундук теләк теләп калырга ашыкты. Әмма Гөлкәй барыбер клубтан Альберт белән кайтып китте...

Унынчы класс укучысы Җиһангир Әхмәтгәрәев химиядән имтихан бирергә бара. Сөеклесе турында уйлап йөреп әзерләнмәде ул. Башы буп-буш. Черегән кабак шикелле. Малай аңкы-миңке кыяфәттә, букчасын аркасына асып, аякларын көчкә сөйрәп, мәктәпкә атлый.

Ярый, ул атлый торсын, ә мин сезгә бүген иртәнге биштә булган хәлне сөйләп китим әле. Җиһангирларның күршесендә яшәүче Маһикамал әбинең өендә мич арасында адашып йөргән таракан белән сулы чиләк үзара сөйләшә башлады:

– Кеше дигәнең бигрәк юләр инде!

– Ник алай дисең, чиләк дустым?

– Күршедә унбиш яшьлек Җиһангир исемле егет яши. Бүген аның имтиханы, ә егетебезнең башында җилләр уйный. Ул

ырым-шырымнарга ышана. Мәктәпкә барганда тулы чиләк күтәргән берәр апайны очратмам микән дип, ашыкмый гына атлаячак, менә күрерсең...

– Һе, – диде таракан. – Әйдә, кызык итәбез үзен!

– Ничек?

– Мин хәзер сиңа төшәм. Иртән Маһикамал әбинең килене, мине күргәч, суыңны түгеп, иртүк чишмәгә китәчәк һәм кайтканда Җиһангирны очратачак. Ырымнарга ышанып, «икеле» алсын әле теге ялкау малай.

...Судан кайтучы киленгә балкып сәлам бирсә дә, юлы уңмады егетнең – авызыннан бер сүз чыкмаган малайга зур «берле» чәпәделәр. Шулай да, өч көннән кабат килеп карарга куштылар.

Шул өч көндә башын бәрә-бәрә укыды малай. Менделеевның үзен күреп сөйләшкәндәй булды хәтта. Әмма 25 билетның яртысын гына хәтерләп кала алды.

Һәм менә Җиһангир кабат мәктәпкә атлый. Күз алдында формулалар, колбалар һәм... Гөлкәйнең алсу йөзе.

Шушы ук мизгелдә мәктәп баскычы астында яшәүче берсе ак, берсе кара ике песи арасында мондый сөйләшү булып алды:

– Кеше дигәнең бигрәк юләр инде, – диде кара песи, тәпиен ялап. Әнә күрәсеңме, Җиһангир исемле малай мәктәпкә таба килә? Хәзер мин шуның юлын аркылы кисеп үтәм һәм ул калтырап төшәчәк. Кире өенә сыпыртуы да бар әле, хе-хе-хе... Мырррр...

– Ә мин җәллим аны, – диде ак песи, авыр сулап. – Начар егет түгел ул. Теге авыл башында торучы рәхимсез Альберт минем бәләкәчләремне суга батырмакчы иде, шушы Җиһангир гына коткарып калды. Әйдә, киресенчә, ярдәм итик без аңа.

Юлына аркылы килеп маташкан кара песине күреп, Җиһангир адымнарын тизләтте, аннары йөгерә үк башлады. «Тизрәк, тизрәк... Аһ, кара мәче!» Әмма тегесе дә шәп йөгерә иде шул. Менә аларның юллары кисеште һәм Җиһангир песигә абынып, тузанлы юлга килеп тә төште. Егетнең күзеннән очкыннар сибелде, ул бер мизгелгә генә аңын югалткан кебек булды. Күзен ачканда, аңа ак песи карап тора иде.

– Тсс.. – диде песи, мырылдап. – Бер сүз дәшмә. Тыңла. Мин гадәти түгел, ә тылсымлы песи. Бар нәрсәне алдан күрәм. Сиңа химиядән сигезенче билет эләгәчәк. Син аны өйрәндең. Борчылма, каушамый гына сөйләп чык. «Дүртле» алырсың. Альберт белән Гөлкәй талаштылар. Кичә Альберт бүтән кызны озаткан. Бүген үк Гөлкәй янына бар. Кыю бул. Хисләреңне әйтергә оялма. Җебеп төшмә! Барысы да үзеңнән тора. Ә ырым-шырымнарга беркайчан да ышанма! Уңышлар сиңа...

Төш идеме бу, өнме – Җиһангир анысын аңламады. Урыныннан торганда әйләнә-тирәдә ак песи дә, кара песи дә күренмәде. Әмма егет хәзер нишләргә кирәген тәгаен белә иде!

Алмаз ГЫЙМАДИЕВ

Сорау – җавап

Дүрт аяклы дус кирәк...

7 яшьлек кызым йорт хайваны алырга сорый. Эт яки песи баласы алып кайтыйк, ди. Аның эш-мәшәкате күп бит, карарга вакытыбыз да юк. Бу очракта нишләргә? Балага рөхсәт итәргәме яисә ничек дөрес итеп аңлатырга?

ЛЮЦИЯ. Казан

Психолог Фәйрүзә ҺАДИЕВА җавап бирә:

– Күп кенә балалар әти-әниләреннән йорт хайваны алып бирүне сорый. Бер яктан, дүрт аяклы дуслар балаларга яхшы яктан тәэсир итә. Алар чын гаилә дустына әйләнә, балага психологик, социаль, биологик юнәлешләрдә ярдәм итә. Йорт хайваны тоту баланы тәртипкә һәм җаваплылыкка өйрәтә. Икенче яктан, өйдә кечкенә җанвар барлыкка килү – аны карарга, тәрбияләргә кирәк дигән сүз. Шуңа күрә, бала йорт хайваны сораган очракта, аңа боларны алдан ук аңлату кирәк. Ул хайванның уенчык түгел, җанлы икәнен, аның өчен җаваплы булуын аңларга тиеш. Шулай итеп, бала кемнедер кайгыртырга, үз гамәлләренең нәтиҗәсенә төшенергә өйрәнә. Бу бигрәк тә эне-сеңелләре булмаган балалар өчен мөһим.

Дусты белән уйнап, бала үзе дә хәрәкәтләнә, физик яктан үсә. Шулай ук хайваннар стрессны киметә, баланың кәефе яхшыра дигән сүз. Йорт хайваннары акыл үсешенә дә тәэсир итә. Кече яшьтән үк бала дусты белән дөньяны өйрәнә башлый. Үзенең җанварын күзәтеп, ул башка хайваннар турында, кешеләр, гомумән, әйләнә-тирә мохит хакында яңа мәгълүматлар белә.

Смайликлар сүзлеге

>> елмаю	>> битараф булу
>> көлү	>> сүзсез калу
>> ырҗаю	>> шаккату
>> күз кысу	>> ачулану
>> кайгыру	>> елау

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 14047 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 332

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+